**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 ноябрендәге 4739 номерлы карары**

**«2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү»**
**муниципаль программасын раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 декабрендәге 997 номерлы «“Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү” Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»гы карарын үтәү йөзеннән, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының 2017 елның 3 маендагы 1640 номерлы «2030 елга кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын раслау турында»гы карарын башкару максатыннан **карар бирәм**:

1. «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын (әлеге карарга 1 номерлы кушымта) расларга.

2. «Мәдәният» тармагы буенча чаралар уздыру өлешендә Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе һәм аның карамагындагы учреждениеләр, шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре эшчәнлеген тәэмин итү белән бәйле чыгымнарны күрсәтелгән программа кысаларында һәм, тиешле бюджет классификациясен кулланып, чираттагы финанс елына бюджетта исәпкә алына торган чаралар чикләрендә гамәлгә ашырырга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсенә:

3.1. квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә

«2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында әлеге карарга 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча хисап тапшырырга;

3.2. квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлегенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы кысаларында шәһәрнең мәдәният учреждениеләре объектларында куркынычсызлыкны һәм аларның террорчылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшырырга;

3.3. ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат тапшырырга;

3.4. «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын финанс белән тәэмин итү күләмнәрен үзгәртү буенча тәкъдимнәрне Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә билгеләнгән тәртиптә тапшырырга.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының районнар администрацияләре башлыклары Р.Х.Шәмсетдиновка, А.И.Салиховка, Р.Р.Фәтхетдиновка, В.В.Жаворонковка квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның унынчы көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында әлеге карарга 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча хисап тапшырырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы –**
**беренче урынбасар** **А.Р.Нигъмәтҗанов**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 20 ноябрендәге
4739 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**«2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү»**
**муниципаль программасы**

## I. Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Муниципаль заказчы | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Мәдәният идарәсе) |
| Программаны төп эшләүче | Мәдәният идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Мәдәният идарәсе, Казан шәһәренең Мәдәният идарәсе карамагындагы бюджет һәм автоном учреждениеләре, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе |
| Программаның максаты | Дөньядагы иң яхшы тәҗрибәләр нигезендә формалашкан һәм шәһәр халкы ихтыяҗларына җавап бирә торган заманча шәһәр мәдәни мохитен комплекслы үстерү |
| Программаның бурычлары | Мәдәният инфраструктурасын үстерүнең сыйфатлы яңа дәрәҗәсен тәэмин итү. |

<table>
<tr><td></td><td>Шәһәр халкының иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру.<br>Мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрне цифрлаштыру һәм мәгълүмати киңлек формалаштыру</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары</td><td>2025-2029 еллар</td></tr>
<tr><td>Ярдәмче программалар исемлеге</td><td>1. «Музей эшен үстерү» (Программага 3 номерлы кушымта).<br>2. «Китапханә эшен үстерү» (Программага 4 номерлы кушымта).<br>3. «Мәдәният-ял итү учреждениеләрен һәм концерт оешмаларын үстерү» (Программага 5 номерлы кушымта).<br>4. «Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре системасын үстерү» (Программага 6 номерлы кушымта).<br>5. «Мәдәният өлкәсендә башка мәсьәләләр» (Программага 7 номерлы кушымта)</td></tr>
<tr><td>Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме</td><td>Программаны финанслауның гомуми күләме 11 682 357,0 мең сумны тәшкил итә, шуларның 9 677 107,0 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 2 005 250,0 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән, 0,0 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауда катнашу.<br><br>
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="4">Акча күләме, мең сумнарда</th></tr>
<tr><th>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th><th>Бюджеттан тыш акчалар</th><th>Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауда катнашу</th><th>Барлыгы</th></tr>
</table></td></tr>
</table>

| | | Барлыгы | шул исәптән Аппаратны карап тотуга чыгымнар | | | Барлыгы | шул исәптән Аппаратны карап тотуга чыгымнар | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Барлыгы | шул исәптән оешмалар милкенә салымны һәм жир салымын түләү | | | | |
| | 2025 | 1 924 854,6 | 12 015,2 | 664,7 | 401 050,0 | 0,0 | 0,0 | 2 325 904,6 |
| | 2026 | 1 938 063,1 | 12 412,3 | 664,7 | 401 050,0 | 0,0 | 0,0 | 2 339 113,1 |
| | 2027 | 1 938 063,1 | 12 412,3 | 664,7 | 401 050,0 | 0,0 | 0,0 | 2 339 113,1 |
| | 2028 | 1 938 063,1 | 12 412,3 | 664,7 | 401 050,0 | 0,0 | 0,0 | 2 339 113,1 |
| | 2029 | 1 938 063,1 | 12 412,3 | 664,7 | 401 050,0 | 0,0 | 0,0 | 2 339 113,1 |
| | **БАРЛЫГЫ** | **9 677 107,0** | **61 664,4** | **3 323,5** | **2 005 250,0** | **0,0** | **0,0** | **11 682 357,0** |

Искәрмә: Программаны финанслау күләме фаразлау характерында. Аңа, тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре

| | |
|---|---|
| | муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш |
| Программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- 2029 елда мәдәни чараларга йөрүләр санын, 2024 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 1,6 тапкырга арттыру;<br>- 2029 елда мәдәният өлкәсендә цифрлы ресурсларга мөрәҗәгать итүләр санын 4 тапкырга арттыру (2024 ел дәрәҗәсе белән чагыштырганда) |

## II. Программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, Казан шәһәренең мәдәният өлкәсендә өстенлекле юнәлешләр һәм төп проблемалар, аларны хәл итү юллары

Әлеге Программа Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы «2030 елга кадәрге чорга һәм 2036 елга кадәрге перспективага Россия Федерациясен үстерүнең илкүләм максатлары турында»гы указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 11 сентябрендәге 2501-р номерлы боерыгы, 2030 елга кадәрге чорга дәүләтнең мәдәният сәясәте стратегиясе, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2014 елның 8 августындагы 4720 номерлы «Казан шәһәре муниципаль программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары, Казан шәһәре Думасының 2016 елның 14 декабрендәге 2-12 номерлы карары белән расланган 2030 елга кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисади үсеш стратегиясе нигезендә эшләнде.

Шәһәрнең мәдәни потенциалы муниципаль, дәүләт, шәхси оешмаларның тулы бер конгломератын үз эченә ала:

- 478 юридик зат (дәүләт, муниципаль мәдәният учреждениеләре һәм башкалар);

- 810 эшмәкәр шәһәрнең мәдәният өлкәсендә эшли.

Хәзерге вакытта муниципаль челтәр 51 юридик заттан (107 объект) гыйбарәт:

- Казан шәһәренең музей комплексы (6 музей);

- Үзәкләштерелгән китапханә системасы (2 үзәк китапханә, 47 филиал һәм 3 китапханә пункты);

- 19 мәдәният-ял итү учреждениесе;

- 3 концерт оешмасы (С.Гобәйдуллинаның Заманча музыка үзәге, La Primavera Казан камера оркестры, Казан шәһәр филармониясе);

- Казан зооботаника бакчасы;

- Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе;

- 10 балалар музыка мәктәбе, 8 балалар сәнгать мәктәбе һәм 7 балалар рәсем сәнгате мәктәбе.

Казан шәһәренең муниципаль мәдәният учреждениеләрендә 2518 хезмәткәр эшли, шуларның 70 проценты (1762 белгеч) – югары белемгә, 20 проценты (503 белгеч) урта махсус белемгә ия. Казан шәһәренең мәдәният учреждениеләрендә эшләүче 145 хезмәткәр Өстәмә һөнәри белем бирү институтында социомәдәни өлкә һәм сәнгать белгечләре сыйфатында квалификацияләрен күтәрде. Хәзерге вакытта Казан шәһәренең мәдәният учреждениеләрендә 40 яшькә кадәрге 900 белгеч эшли. 2023 елда яңа кабул ителгән белгечләр саны 459 кешегә җитте.

Казан – сәнгать һәм мәдәният аерым урын били торган шәһәр. Татарстан Республикасы башкаласы ел саен дөньякүләм мәдәни чаралар үзәгенә әверелә. Әлеге чаралар арасында Ф.И.Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивален, Рудольф Нуриев исемендәге Халыкара классик балет фестивален, Сергей Рахманинов исемендәге «Ак сирень» халыкара фестивален һәм Казан халыкара мөселман киносы фестивален атап узарга мөмкин.

Казан музейлары илнең иң эре музейлары – Дәүләт Эрмитажы, Дәүләт Третьяков галереясы, Дәүләт Рус музее белән уртак проектларны гамәлгә ашыра. Музей өлкәсендә Казан шәһәре Мэриясе ярдәме белән хосусый-дәүләти партнерлык проектлары уңышлы гамәлгә ашырылды. Василий Аксенов музей-йортын, социалистик көнкүреш музеен һәм Константин Васильев музеен ачу шундыйлардан.

Дәүләтнеке булмаган театрлар сегменты да үсә. Казанның SDVIG камера театры шәһәр үзәгендә йортлы булды. «“Анна Каренина” иммерсив тамашасы» проекты элеккеге үзәк гражданлык хәле актларын теркәү бинасын яңа сыйфатта файдалану мөмкинлеге тудырды. Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең яңа бинасында МОÑ театр мәйданчыгы ачылды.

Дәүләтнеке булмаган күргәзмә экспозиция проектлары: Казан панорамасы, «Бизон» галереясы һәм «Дом ART» барлыкка килде. «Казан ярминкәсе»

күргәзмәләр үзәге территориясендә мультимедиалы «Россия – минем тарих» тарихи паркы ачылды.

Игорь Крутойның Популяр музыка академиясе классик мәктәпкә альтернатива буларак зур кызыксыну тудырды. Рок мәктәбе дә мөстәкыйль учреждение сыйфатында эшли башлады. К.Ю.Хабенскийның «Оперение» театр студиясе муниципаль бюджеттан финанслау алды.

Казанда Пушкин исемендәге мәдәният үзәге ачылды. Ә Заманча сәнгать галереясы Казанда заманча сәнгать юнәлешендә махсуслашкан иң эре күргәзмә мәйданчыгы буларак танылды. Кариев исемендәге Татар яшь тамашачы театры яңа театр-йортка күченде, Алафузовның элеккеге театры исә хәзер Созвездия-Йолдызлык өчен арт-резиденция. Казан циркында масштаблы реконструкция үткәрелде. Казан зооботаника бакчасының яңа территориясе эшли башлады.

Бүгенге көнгә Казанның барлык мәдәният сарайлары да тулысынча ремонтланган. Комплекслы яңарту программасына иң эре алты учреждение керде. Алар арасында өч мәдәни мирас объекты бар. Якын-тирәдәге районнарда яшәүчеләр үтенече белән әлеге объектларда кинотеатрлар торгызылды. Болар – Ленин исемендәге мәдәни-ял итү комплексы, С.Сәетгалиев исемендәге мәдәният сарае һәм Тимерьюлчылар мәдәният сарае. «Мәскәү» һәм «Сәйдәш» мәдәният үзәкләренең эчке киңлекләре тулаем үзгәртелде, аларга яңа сулыш өрелде. 2020 елда «Залесный» мәдәният үзәге төзекләндерелде. Комплекслы программага кергән соңгы объект «Чулпан» мәдәният үзәге булды. Ул «Казан» бию ансамбленең һәм Казан шәһәр филармониясенең төп концерт һәм репетиция мәйданчыгына әверелде.

«Авыл клублары» республика программасы буенча яңа мәдәният йортлары төзү эше дәвам итте. Кадыш, Вознесение, Северный, Красная Горка, Мирный, Нагорный, Отар, Константиновка торак массивларында барлыгы 8 учреждение төзелде.

Шәһәр мәдәният үзәкләрен модернизацияләү барышында түгәрәкләр һәм коллективлар саны ике тапкырга артты. Социомәдәни инициативаларга һәм халыкның төрле төркемнәрен үз эченә алган һәвәскәрләр иҗатына ярдәм итү максатыннан 2023 елда Казанда 737 клуб берләшмәсе үз эшчәнлеген гамәлгә ашырды, аларда барлыгы 14304 кеше исәпләнә. Шуларның 476 сы – үзешчән халык иҗаты берләшмәләре, шул исәптән 316 сы – 14 яшькә кадәрге балалар өчен, аларга 5860 кеше җәлеп ителгән.

2023 елда Казан шәһәренең мәдәният-ял итү төрендәге учреждениеләре көче белән 6396 чара уздырылды (мәдәният-ял итү чараларының гомуми санынннан 2463 е – 14 яшькә кадәрге балалар өчен).

«Казан шәһәре мәдәниятен үстерү» программасы кысаларында 130 дан артык программа чарасы оештырылды. Аларның иң эреләре: Җиңү көненә, Россия көненә

багышланган чаралар, Сабан туе, Май чабу бәйрәме, Нәүрүз, Татарстан Республикасы көне, Китап-фест, Яңа елны бәйрәм итү белән бәйле чаралар һ.б. Биш ел эчендә гомумшәһәр чараларының тамашачылар аудиториясе 3 миллионнан артык кешене тәшкил итте, әлеге күрсәткечне футбол матчларына йөрүчеләр саны белән чагыштырырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Рәисе йөкләмәләрен үтәү кысаларында 2023 елда шәһәрнең балалар сәнгать мәктәпләрен һәм китапханәләрне капиталь ремонтлау программасын гамәлгә ашыру дәвам итте. «Гаилә» атамасы белән яңартылган 27 номерлы китапханә һәм 2 номерлы балалар сәнгать мәктәбе ачылды. Моннан тыш, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе тарафыннан Татарстан Республикасында игълан ителгән Милли мәдәниятләр һәм традицияләр елын әзерләү һәм уздыру буенча комплексы план гамәлгә ашырылды. Муниципаль мәдәният учреждениеләре көче белән 1300 чара оештырылды.

2023 елда муниципаль мәдәният учреждениеләре составы Казан шәһәренең «“Апуш” балалар татар театр студиясе» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе төзелү хисабына артты.

Мәдәният идарәсе 25 балалар сәнгать мәктәбе (10 музыка, 8 сәнгать, 7 рәсем сәнгате мәктәбе) эшен координацияли, аларда хәзерге вакытта 8423 яшь казанлы бушлай белем ала. Яшьләр симфоник оркестры маэстро Александр Сладковский ярдәме белән уңышлы гастроль эшчәнлеге алып бара.

Соңгы биш елда шәһәрнең балалар музыка һәм сәнгать мәктәпләрендә тәрбияләнүче 75 сәләтле бала Казан шәһәре Мэры стипендиаты булды. Чайковский исемендәге 1 номерлы балалар музыка мәктәбе Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы версиясе буенча Россиянең иң яхшы мәктәпләре рейтингына керде.

Муниципаль концерт учреждениеләре Казанның мәдәни образын тәшкил итүче мөһим элемент булып тора.

La Primavera оркестры үзенең масштаблы фестивальләре һәм уникаль проектлары белән билгеле. Камера оркестры чыгышы ЮНЕСКОның «Мәдәният COVID-19 га каршы» проектына керде һәм ЮНЕСКОның иҗади шәһәрләре сайтында урнаштырылды.

София Гобәйдуллина исемендәге Заманча музыка үзәге дә креатив мәйданчык булып тора. Биредә үзәкнең камера оркестры катнашында концертлар һәм фестивальләр уза, аларга Россиянең әйдәп баручы музыкантлары һәм композиторлары чакырыла. 2020 елда ЮНЕСКО эгидасы белән гамәлгә ашырыла торган яңа проект – Халыкара яшь композиторлар конкурсы старт алды. Анда 14 илдән һәм Россиянең 32 төбәгеннән вәкилләр катнашты.

Казан шәһәр филармониясе эшчәнлеге татар милли мәдәниятен саклап калуга һәм үстерүгә, киләчәккә төбәлгән яңа мәдәни мирас булдыруга юнәлдерелгән. Ел

саен Казан шәһәр филармониясенең иҗат коллективлары тарафыннан 20 дән артык концерт куела, аларны 10 меңгә якын тамашачы карый.

Шактый зур капитал кертемнәр аерым нәтиҗәлелек һәм киләчәктә Казанның мәдәният тармагын үстерүдә сыйфатлы күрсәткечләргә ирешүне таләп итә. Бүген беренче карашка Казанның мәдәният үсешендә уңай картина күзәтелә, һәм, матди-техника базаны яңартканнан соң, муниципаль мәдәният учреждениеләренең уңышлы эшчәнлек алып баруына да мисаллар җитәрлек.

Җәмәгать киңлекләрендә мәдәният булу – сыйфатлы шәһәр мохитенең төп үзенчәлекләреннән берсе. Мәдәни активлыкны стимуллаштыру буенча халыкара форматларның берсе – урам музыкантлары чыгышлары өчен инфраструктураны үстерү. Урамда киңлекләрне маркировкалау һәм чыгышларны килештерү какофония булдырмаска һәм музыкантларга үз эшләрен оештыру өчен уңайлы шартлар тудырырга мөмкинлек бирә. Казан, ЮНЕСКО музыкасы шәһәре буларак, үз йөзен һәм яңгырашын табачак.

2019 ел ахыры – 2020 елның беренче яртысында «Казанның мәдәни тормышына аудит» уздырылды. Тикшерү кысаларында 38 дәүләт һәм муниципаль мәдәният учреждениеcе һәм кайбер дәүләтнеке булмаган институтларның эшчәнлеге җентекләп өйрәнелде. Шәһәр күләмендә оештырылган сораштыру күрсәткәнчә, пандемия алдыннан Казанның мәдәният инфраструктурасына ихтыяҗ тулаем алганда түбән булган. Казанлылар арасында яңартылган паркларга, скверларга һәм яр буйларына ихтыяҗ зур, ә мәдәният учреждениеләре халыкның 30 процентын гына җәлеп итә.

Яшьләр арасында мәдәният учреждениеләренә карата булган битарафлык борчу тудыра. 18 яшьтән 25 яшькә кадәрге казанлыларның 17 проценты гына театрларга, музейларга, күргәзмәләргә һәм концертларга йөри. Яшь казанлылар буш вакытларын өйдә уздыруны өстенрәк күрәләр.

Казанлыларның 45 проценты бер генә мәдәният учреждениесендә дә булмаган, аларның мәдәни активлыгы нульгә тигез. Чагыштыру өчен: мәскәүлеләр арасында мәдәни активлыгы нульгә тигез булганнар 31 процентны тәшкил итә. Казанда ир-атлар арасында мәдәни активлыгы нульгә тигез булганнар хатын-кызлар белән чагыштырганда 1,5 тапкырга күбрәк (55% һәм 37%). Казанлыларның бары 12 проценты гына, ярты елга бер тапкыр булса да, өч яки аннан да күбрәк төрле типтагы мәдәният учреждениеләренә йөри.

Үткәрелгән тикшеренү нәтиҗәләре шуны күрсәтә: шәһәргә гомуми мәдәни дәрәҗәне арттыруга һәм интеллектуаль ялны стимуллаштыруга юнәлеш алу мөһим.

Якын киләчәк таләбе, һичшиксез, хезмәтләрне цифрлаштыру булачак. Ул пандемия шартларында үзенең актуальлеген күрсәтте инде.

14 яшьтән 22 яшькә кадәрге балаларны һәм яшьләрне сәнгати мәдәниятне һәм сәнгатьне өйрәнүгә актив җәлеп итү, аларда илебез һәм дөнья мәдәнияте кыйммәтләрен үзләштерүгә кызыксыну уяту, үсеп килүче буынның мәдәнилек дәрәҗәсен күтәрү максатыннан илдә «Пушкин картасы» проекты гамәлгә ашырыла. Әлеге проект кысаларында чаралар үткәрү өчен учреждение җитәкчеләре актив рәвештә «PRO.Культура.РФ» сервисыннан файдалана һәм чараларга билетларны онлайн сата башлады.

Хәзерге вакытта мәдәният сарайларында эшли торган түгәрәкләр һәм алар тарафыннан күрсәтелә торган башка хезмәтләр өчен онлайн-түләү мөмкинлеге бар. Муниципаль мәдәният учреждениеләренең мәдәният белән бәйле берләштерелгән барлык тәкъдимнәрен киләчәктә бердәм портал һәм телефон кушымтасы аша карап булачак.

Югрыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Казан шәһәрендә мәдәният өлкәсен үстерүнең түбәндәге өстенлекләрен аерып күрсәтергә мөмкин:

- муниципаль музейларның җәлеп итүчәнлеген арттыру һәм алар эшендә яңа интерактив практикаларны кулланышка кертү;

- муниципаль мәдәният сарайларын модернизацияләү һәм шәһәр мәдәният йортлары эшчәнлеге принципларын сыйфат ягыннан үзгәртү;

- китапханәләр эшендә трансформация процесслары, алардан шәһәр халкы өчен яңа җәмәгать урыннары һәм нәтиҗәле челтәр булдыру;

- сәнгать өлкәсендә академик башлангыч белем бирү системасын саклаган хәлдә, муниципаль сәнгать мәктәпләре челтәре базасында өлкәннәргә белем бирүне үстерү;

- шәһәрдә яшәү, эшләү һәм ял итү өчен уңайлы шартлар тудыру, шәһәрнең ачык киңлекләрендә фестивальләр һәм чаралар уздыру өчен инфраструктураны үстерү.

## III. Гамәлгә ашыру вакытын күрсәтеп, Программаның максаты һәм бурычлары, ярдәмче программаларның исемлеге һәм кыскача тасвирламасы

Программаның максаты – дөньядагы иң яхшы тәҗрибәләр нигезендә формалашкан һәм шәһәр халкы ихтыяҗларына җавап бирә торган заманча шәһәр мәдәни мохитен комплекслы үстерү.

Әлеге максатка ирешү өчен системалы характердагы берничә мәсьәләне хәл итү зарур. Аларга түбәндәгеләр керә:

1) мәдәният инфраструктурасын үстерүнең сыйфатлы яңа дәрәҗәсен тәэмин итү;

2) шәһәр халкының иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;

3) мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрне цифрлаштыру һәм мәгълүмати киңлек формалаштыру.

Әлеге бурычларны хәл итү максатыннан, шулай ук мәдәният учреждениеләренең күптөрлелеген исәпкә алып, түбәндәге ярдәмче программалар билгеләнде:

1. Музей эшен үстерү.

2. Китапханә эшен үстерү.

3. Мәдәният-ял итү учреждениеләрен һәм концерт оешмаларын үстерү.

4. Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре системасын үстерү.

5. Мәдәният өлкәсендәге башка мәсьәләләр.

Бурычлар буенча Программаның нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары исемлеге Программага 1 номерлы кушымтада китерелә.

Программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2025-2029 еллар.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын файдалануны һәм бюджеттан тыш акчаларны җәлеп итүне күздә тота.

Программаны финанслауның гомуми күләме 11 682 357,0 мең сумны тәшкил итә, шуларның 9 677 107,0 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 2 005 250,0 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән, Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауда катнашу ел саен анықланачак.

Бюджеттан тыш акчалар эшмәкәрлек эшчәнлегеннән һәм керем китерә торган башка төр эшчәнлектән акчалар күчерү һәм аларны тоту өчен каралган эшмәкәрлек эшчәнлегеннән алынган акчаларны исәпкә алу буенча казначылык счетлары ачуга рөхсәт нигезендә муниципаль мәдәният учреждениеләренең Татарстан Республикасы Казначылык департаментының территориаль органында ачылган шәхси счетларына күчерү юлы белән керә.

Муниципаль мәдәният учреждениеләренең бюджеттан тыш акчаларны тотуын контрольдә тотучы органнар – Мәдәният идарәсе, финанс органнары, Татарстан Республикасы Казначылык департаментының территориаль органы. Бюджеттан тыш акчаларны файдалану турында хисап «Барс Web- җыентык» программа комплексында түбәндәге формалар буенча төзелә:

- 155 – «Бюджет учреждениеләрендә, автоном учреждениеләрдә һәм башка оешмаларда кассага акча керү һәм акчаның чыгуы турында хисап»;

- 19 – «Түләүле хезмәтләр күрсәтүдән кергән керемнәр буенча мәгълүмат».

Юридик һәм физик затлардан иганәчелек яки хәйрия ярдәме рәвешендә финанс ярдәме кергән очракта, акчалар «Грантлар, премияләр, ирекле иганәләр» счетында исәпкә алына һәм 155 формадагы хисапларда чагыла.

Программаны гамәлгә ашырыла торган ярдәмче программалар киселешендә финанслар белән тәэмин итү Программага 2 номерлы кушымтада китерелә.

Программаны гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү фаразлау характерында һәм аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. Программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программа чараларын гамәлгә ашыру барышында муниципаль заказчы төп башкаручыларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә, чараларны гамәлгә ашыру барышын һәм турыдан-туры башкаручылар тарафыннан акчаларны нәтиҗәле файдалануны контрольдә тота. Программа чараларын гамәлгә ашыру Программа заказчы тарафыннан Программа чараларын үтәүчеләрнең барысы белән дә төзелә торган муниципаль контрактлар нигезендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына катгый рәвештә туры китереп, шулай ук муниципаль учреждениеләр өчен билгеләнә торган муниципаль биремнәр нигезендә башкарыла.

Программаның муниципаль заказчысы:

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә карарга 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча Программаны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшыра;

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлегенә Программа кысаларында шәһәрнең мәдәният учреждениеләре объектларында куркынычсызлыкны һәм аларның террорчылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшыра;

- ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Программаны гамәлгә ашыру,

шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат тапшыра;

- Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Программаны финанс белән тәэмин итү күләмнәрен үзгәртү буенча тәкъдимнәрне билгеләнгән тәртиптә тапшыра;

- хисап елыннан соң килә торган елның 1 июненнән дә соңга калмыйча, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында Программаны гамәлгә ашыру турында еллык хисап урнаштыра.

Программаны үтәүдә катнашучылар (Казан шәһәренең Мәдәният идарәсе карамагындагы бюджет һәм автоном учреждениеләре, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе) квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның унынчы көненә кадәр, Мәдәният идарәсенә карарга 2 номерлы кушымта нигезендә билгеләнгән форма буенча Программаның үтәлеше турында хисап тапшыралар.

## VI. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

Мәдәни эшчәнлек нәтиҗәләре вакыт буенча кичектерелгән социаль тәэсир көченә ия, алар интеллектуаль мөмкинлекләр артуда, гражданнарның әхлакый кыйммәтләре һәм үз-үзләрен тоту кагыйдәләре үзгәрүдә чагыла, бу ахыр чиктә җәмгыятьнең дә яшәеш нигезләре үзгәрүгә китерә.

Программада мәдәният учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген характерлаучы индикаторлар һәм цифрлы күрсәткечләр системасын, мәдәни эшчәнлек нәтиҗәлелегенең төп күрсәткечләрен файдалану күздә тотыла. Шул ук вакытта Программада эшчәнлекнең агымдагы күрсәткечләре китерелә. Программаны һәм аның ярдәмче программаларын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге Программаның муниципаль заказчысы тарафыннан бәяләнә.

Программаны гамәлгә ашырудан төп социаль-икътисади нәтиҗә казанлылар тормышында мәдәниятнең социаль ролен арттыруда һәм шәһәрдә тормыш сыйфатын күтәрүдә, мәдәният өлкәсендә модернизацияләү курсын гамәлгә ашыру өчен уңайлы атмосфера тудыруда чагыла.

Кичектерелгән гамәлнең нәтиҗәлелеге:

- Казан шәһәрендә яшәүче халыкларның мәдәни киңлек бердәмлеген ныгытуда, бөтенлеген, үзенчәлеген саклауда;

- заманча мәдәният учреждениеләрендә гражданнарның иҗади үсеше һәм үз мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыруда, шулай ук мәдәни кыйммәтләрдән тагын да киңрәк файдалану мөмкинлеге булдыруда;

- Россия гражданлык тәңгәллеген ныгытуга юнәлтелгән иҗади инициативаларга ярдәм итүдә һәм рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклауда;

- мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашу юлы белән балаларны һәм яшьләрне рухи-әхлакый яктан үстерүне оештыруда;

- халыкларның рухи-әхлакый кыйммәтләре, тарихи һәм милли-мәдәни кыйммәтләр нигезендә гармонияле үсеш алган һәм социаль яктан җаваплы шәхес тәрбияләү өчен уңай шартлар булдыруда;

- балаларның һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачыклауның, аларга ярдәм итүнең һәм аларны үстерүнең гаделлек, гомумилек принципларына нигезләнгән һәм барлык укучыларның үзбилгеләнүенә һәм аларга һөнәри юнәлеш бирүгә юнәлдерелгән нәтиҗәле системасын формалаштыруда;

- мәдәният тармакларын, шул исәптән мәгълүмат технологияләрен киң кулланышка кертү аша да, инновацион үсеш юлына күчерүдә, мәдәниятне иҗтимагый эшчәнлекнең аеруча алга киткән, үзенә җәлеп итә торган өлкәсенә әверелдерүдә;

- «Музыка» юнәлеше буенча ЮНЕСКОның креатив шәһәрләре челтәренә кергән Казанның мәдәни башкала буларак имиджын ныгытуда чагылачак.

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге Программа белән расланган максатчан индикаторларга һәм күрсәткечләргә фактта ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

Программаны гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- 2029 елда мәдәният өлкәсендә цифрлы ресурсларга мөрәҗәгатьләр санын 4 тапкырга арттыру. Күрсәткечне исәпләп чыгару төп цифрлы ресурсларга карата башкарыла. Алар: «Культура.РФ» Россия халыкларының мәдәни мирасын һәм традицияләрен популярлаштыруның бердәм порталы, «История.РФ» тарихны популярлаштыру порталы, «НЭБ РФ» Милли электрон китапханә порталы, Россия Федерациясе Музей фондының Дәүләт каталогы (goskatalog.ru), музейлар һәм күргәзмә проектлары буенча чынбарлык белән тулыландырылган «Артефакт» цифрлы гидлар платформасы, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы карамагындагы башка мәдәният оешмаларының рәсми сайтлары һәм мәгълүмат ресурслары;

- 2029 елда мәдәни чараларга йөрүләр санын, 2024 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 1,6 тапкырга арттыру. Күрсәткеч натураль берәмлекләрдә үлчәнә, ул шәһәр территориясендәге барлык төр учреждениеләр тарафыннан уздырыла торган мәдәни чараларга йөрү буенча күрсәткечләрнең суммасы булып тора һәм бер кешенең түләүле нигездә һәм бушлай оешманың үз бинасында һәм аннан читтә, шул исәптән онлайн-форматта уздырыла торган төрле чараларга шәхсән килүен исәпкә ала (бары рәсми цифрлы ресурслардан гына).

Күрсәткеч түбәндәге формула буенча исәпләнә:

I(t) + A(t) + B(t) + C(t) + D(t) + E(t) + F(t) + G(t) + H(t) + J(t) + K(t) + L(t) + M(t) + M(t) + N(t), биредә:

I(t) – мәдәни чараларга йөрүләрнең гомумиләштерелгән саны;

A(t) – китапханәләргә йөрүләр саны;

B(t) – мәдәният-ял итү тибындагы учреждениеләрнең һәм башка оешмаларның массакүләм мәдәни чараларына йөрүләр саны;[1]

C(t) – музейларга йөрүләр саны;

D(t) – театрларга йөрүләр саны;

E(t) – мәдәният һәм ял паркларына йөрүләр саны;

F(t) – концерт оешмаларына һәм мөстәкыйль коллективларга йөрүләр саны;

G(t) – циркларга йөрүләр саны;

H(t) – зоопаркларга йөрүләр саны;

J(t) – кинотеатрларга йөрүләр саны;

K(t) – мәдәният өлкәсендә цифрлы ресурсларга мөрәҗәгать итүләр саны, ул «Цифрлы мәдәният» счетчигы мәгълүматлары буенча билгеләнә («Мәдәният өлкәсендә бердәм мәгълүмат киңлеге» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы). Россия Федерациясе субъекты буенча әлеге субъектның цифрлы ресурсларына мөрәҗәгать итүләр саны исәпкә алына. Федераль дәрәҗәдә федераль цифрлы ресурсларга мөрәҗәгатьләр саны һәм «Цифрлы мәдәният» счетчигы урнаштырылган барлык региональ цифрлы ресурсларга мөрәҗәгатьләр санының гомумиләштерелгән күрсәткече исәпкә алына. Әлеге күрсәткечне исәпкә алганда, муниципаль берәмлек дәрәҗәсендә федераль цифрлы ресурсларга мөрәҗәгать итүләр саны һәм «Цифрлы мәдәният» счетчигы урнаштырылган барлык региональ цифрлы ресурсларга мөрәҗәгатьләр санының гомумиләштерелгән күрсәткече алына;

L(t) – сәнгать төрләре буенча балалар сәнгать мәктәпләре тарафыннан үткәрелә торган мәдәни чараларга йөрүләр саны;

---

[1] «Башка оешмалар»га, санап үтелгән учреждениеләрдән кала, эшчәнлекләренең төп төрләреннән тыш, түләүле нигездә һәм бушлай үз биналарында һәм читтә, шул исәптән онлайн-форматта, мәдәни чаралар үткәрүче оешмалар керә.

M(t) – һөнәри белем бирүче оешмалар тарафыннан үткәрелә торган мәдәни чараларга йөрүләр саны;

N(t) – югары белем бирүче мәгариф оешмалары тарафыннан үткәрелә торган мәдәни чараларга йөрүләр саны;

t - мониторинг чоры (квартал).

Күрсәткечләрне исәпләп чыгаруның җентекле методикасы, учреждение төренә карап, һәр ярдәмче программада күрсәтелгән.

______________________

«2025-2029 елларга
Казан шәһәрендә мәдәниятне
үстерү» муниципаль программасына
1 номерлы кушымта

## Программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары

| Максатның атамасы | Бурычның атамасы | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторы, үлчәү берәмлеге | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | База 2024 | план 2025 | план 2026 | план 2027 | план 2028 | план 2029 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Дөньядагы иң яхшы тәҗрибәләр нигезендә формалашкан һәм шәһәр халкы ихтыяҗларына җавап бирә торган заманча шәһәр мәдәни мохитен комплекслы үстерү | Мәдәният инфраструктурасын үстерүнең сыйфатлы яңа дәрәҗәсен тәэмин итү | Мәдәни чараларга йөрүләр саны, мең йөрү (барлык милек формасындагы оешмаларны исәпкә алып) | 16 661,6 | 19 993,9 | 21 660,1 | 23 326,2 | 24 992,4 | 26 658,6 |
| | Шәһәр халкының иҗади потенциалын гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру | Ярдәм күрсәтелгән иҗади инициативалар һәм проектлар саны | 10 | 11 | 12 | 12 | 12 | 12 |
| | | Ирекләләр эшчәнлегендә катнашучы гражданнар саны, кеше | 20 | 21 | 22 | 23 | 23 | 23 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашучылар саны, мең кеше | 102,5 | 102,5 | 102,5 | 102,6 | 102,6 | 102,7 |
| | Мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрне цифрлаштыру һәм мәгълүмати киңлек формалаштыру | Мәдәният өлкәсендә цифрлы ресурсларга мөрәҗәгатьләр саны, мең мөрәҗәгать | 6,0 | 10,2 | 13,8 | 17,4 | 21 | 24 |

«2025-2029 елларга
Казан шәһәрендә мәдәниятне
үстерү» муниципаль программасына
2 номерлы кушымта

## Программаны гамәлгә ашыруны ресурслар белән тәэмин итү

| № т/б | Ярдәмче программа атамасы | Финанслау чыганагы | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | «Музей эшен үстерү» | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 45 299,6 | 45 213,7 | 45 213,7 | 45 213,7 | 45 213,7 | 45 213,7 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 3 000,0 | 3 000,0 | 3 000,0 | 3 000,0 | 3 0000,0 | 3 0000,0 |
| | | Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауда катнашу | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| 2 | «Китапханә эшен үстерү» | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 184 006,6 | 181 806,7 | 181 806,7 | 181 806,7 | 181 806,7 | 181 806,7 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 |
| | | Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауда катнашу | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| 3 | «Мәдәният-ял итү учреждениеләрен һәм концерт оешмаларын үстерү» | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 919 514,4 | 927 813,3 | 937 339,1 | 937 339,1 | 937 339,1 | 937 339,1 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 360 600,0 | 360 600,0 | 360 600,0 | 360 600,0 | 360 600,0 | 360 600,0 |
| | | Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауда катнашу | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |

| № т/б | Ярдәмче программа атамасы | Финанслау чыганагы | 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 4 | «Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре системасын үстерү» | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 691 746,5 | 692 923,8 | 696 142,9 | 696 142,9 | 696 142,9 | 696 142,9 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 37 250,0 | 37 250,0 | 37 250,0 | 37 250,0 | 37 250,0 | 37 250,0 |
| | | Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауда катнашу | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| 5 | «Мәдәният өлкәсендәге башка мәсьәләләр» | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 77 878,1 | 77 097,1 | 77 560,7 | 77 560,7 | 77 560,7 | 77 560,7 |
| | | шул исәптән Аппаратны карап тотуга чыгымнар | 11 633,4 | 12 015,2 | 12 412,3 | 12 412,3 | 12 412,3 | 12 412,3 |
| | | шулардан оешмалар милкенә салым һәм җир салымын түләү | 664,7 | 664,7 | 664,7 | 664,7 | 664,7 | 664,7 |
| | | Бюджеттан тыш акчалар | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| | | Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауда катнашу | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| | | шул исәптән Аппаратны карап тотуга чыгымнар | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |
| **Программа буенча барлыгы,** шул исәптән | | | **2 319 495,2** | **2 325 904,6** | **2 339 113,1** | **2 339 113,1** | **2 339 113,1** | **2 339 113,1** |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | | | 1 918 445,2 | 1 924 854,6 | 1 938 063,1 | 1 938 063,1 | 1 938 063,1 | 1 938 063,1 |
| бюджеттан тыш акчалар | | | 401 050,0 | 401 050,0 | 401 050,0 | 401 050,0 | 401 050,0 | 401 050,0 |
| Татарстан Республикасы бюджеты акчалары | | | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |

«2025-2029 елларга
Казан шәһәрендә мәдәниятне
үстерү» муниципаль программасына
3 номерлы кушымта

## «Музей эшен үстерү»
## 1 нче ярдәмче программасы

## I. 1 нче ярдәмче программа паспорты

<table>
<tr><td>1 нче ярдәмче программа атамасы</td><td>«Музей эшен үстерү» (алга таба – 1 нче ярдәмче программа)</td></tr>
<tr><td>Муниципаль заказчы</td><td>«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Мәдәният идарәсе)</td></tr>
<tr><td>1 нче ярдәмче программаны төп эшләүче</td><td>Мәдәният идарәсе</td></tr>
<tr><td>1 нче ярдәмче программаны башкаручылар</td><td>Мәдәният идарәсе, Казан шәһәренең Мәдәният идарәсе карамагындагы бюджет һәм автоном учреждениеләре</td></tr>
<tr><td>1 нче ярдәмче программаның максаты</td><td>Музей эшчәнлеген заманча мәгълүмати җәмгыять таләпләре нигезендә үстерү</td></tr>
<tr><td>1 нче ярдәмче программаның бурычлары</td><td>Музей эшчәнлегенең төп юнәлешләрен саклаган хәлдә, музейлар белән халык арасындагы хезмәттәшлекнең яңа формаларын эзләү һәм үстерү</td></tr>
<tr><td>1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты</td><td>2025-2029 еллар</td></tr>
<tr><td>Елларга һәм чыганакларга бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләме</td><td>1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 241 068,5 мең сумны тәшкил итә, шуларның 226 068,5 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 15 000,0 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән.
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Акча күләме, мең сумнарда</th></tr>
<tr><th>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th><th>Бюджеттан тыш чаралар</th></tr>
<tr><td>2025</td><td>45 213,7</td><td>3 000,0</td></tr>
</table></td></tr>
</table>

<table>
<tr>
<td></td>
<td>
<table>
<tr><td>2026</td><td>45 213,7</td><td>3 000,0</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>45 213,7</td><td>3 000,0</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>45 213,7</td><td>3 000,0</td></tr>
<tr><td>2029</td><td>45 213,7</td><td>3 000,0</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫ-ГЫ</td><td>226 068,5</td><td>15 000,0</td></tr>
</table>
Искәрмә: 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>1 нче ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 1 нче ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td>
<td>1 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- 2029 елда музейларга йөрүләр санын, 2024 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 1,2 тапкырга арттыру;<br>- ел саен мәдәни-тарихи мирас өлкәсендә бер иҗади инициативага һәм проектка ярдәм итү;<br>- 2029 елда предметларның гомуми саныннан цифрланган музей предметларының чагыштырмача күләмен 56 процентка җиткерүгә ирешү;<br>- мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашучылар санын 2029 елга 850 кешегә кадәр арттыру;<br>- Казан шәһәре музей комплексы базасында иҗади һәм социомәдәни инициативаларны гамәлгә ашыру өчен мәдәният өлкәсендә волонтерлык эшчәнлеген үстерү;<br>- гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар санын 2029 елга 1500 кешегә кадәр арттыру</td>
</tr>
</table>

## II. 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән 1 нче ярдәмче программа хәл итәргә тиешле мәсьәләләр исемлеге

Казан шәһәренең музейлар челтәре составында Константин Васильевның картиналар галереясы, Бакый Урманче музее, Әмир Мәҗитов музее, Илдар Зариповның галерея-студиясе, «Хәтер китабы» мемориалы һәм В.П.Аксенов музей-йорты булган Музей комплексыннан гыйбарәт.

Муниципаль музейлар эшчәнлегенең барлык юнәлешләрен (коллекцияләр туплау, фәнни-фонд һәм архив эше, фәнни-тикшеренү эше, нәшрият эшчәнлеге, экспозиция-күргәзмә эшчәнлеге, фәнни-агарту һәм экскурсия-лекция эшчәнлеге) уңышлы үстерү аларның сыйфатлы һәм нәтиҗәле эшләве өчен бик мөһим.

Музейлар эшчәнлегенең мирас объектларын комплектлаштыруны, исәпкә алуны, саклауны һәм өйрәнүне үз эченә алган әйдәп баручы юнәлешләреннән берсе – фонд эше. 2023 елга музейлар фондлары 50731 саклау берәмлеген үз эченә ала, шуларның 32406 берәмлеге – төп фондка, 18525 берәмлеге фәнни-ярдәмче фондка карый.

2023 елда 30 музей предметы реставрацияләнде. Музейларда – 64, төрле күргәзмә мәйданчыкларында 15 күргәзмә үткәрелде. 2023 елда Казан шәһәренең музей комплексында 98000 кеше булды, шуларның 35000 е – балалар һәм яшьләр. Экспозициянең гомуми мәйданы – 693,2 кв.м. Музей биналарының гомуми мәйданы – 3503,7 кв.м, фонд саклагычы исә 280 кв.м мәйданны били.

Казан шәһәре тарихы белән бәйле күренекле эшлеклеләр истәлеген һәм вакыйгаларны мәңгеләштерү өлешендә дә зур эш алып барыла.

Россия Герое Дамир Нәзир улы Исламов хөрмәтенә Хәрби шәһәрчек-2 территориясендәге 4 номерлы йорт фасадында мурал пәйда булды, Казан югары танк команда училищесында бюст урнаштырылды.

«42 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет мәгариф учреждениесенә Россия Герое Д.Р.Гыйлемханов исеме бирелде, шулай ук әлеге мәктәптә аңа багышланган истәлек тактасы эленде һәм музей почмагы ачылды. Казан югары танк команда училищесының Россия Геройлары аллеясында И.Л.Насыйбуллинга, Д.Э.Шәймәрдановка һәм Ватанның башка геройларына бюстлар урнаштырылды.

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның исемнәрен Казан шәһәренең яшь армиячеләр отрядлары йөртә, шулай ук мәктәп музейларында аларга багышланган музей почмаклары оештырыла.

Ватан геройлары истәлеген мәңгеләштерү эше дәвам итә. Горький урамындагы 3б номерлы йорт фасадында – Кузнецов Борис Кирилловичка, В.Сажинов урамындагы 6/9 номерлы йорт фасадында – Сажинов Виктор Александровичка, Адамюк урамындагы 4 номерлы йорт фасадында – Сафиуллин Гани Биккенә улына, Иовлев урамындагы 7 номерлы йорт фасадында Иовлев Владимир Александровичка мемориаль такталар эленде.

2023 елның 4 маенда Казан-2 тимер юл вокзалы янындагы скверда Татарстан Республикасы Рәисе катнашында «Казан – хезмәт батырлыгы шәһәре» стеласы тантаналы төстә ачылды. «Казан – хезмәт батырлыгы шәһәре» дип аталучы истәлек композициясе ике пилон белән әйләндереп алынган 26 метр биеклектәге стеладан гыйбарәт. Аларда Бөек Ватан сугышы елларында тыл хезмәтчәннәренең батырлыгы турындагы тарихи материаллар чагылыш тапкан.

2023 елның 15 сентябрендә Казан «Россия – геройлар иле» истәлек

эстафетасын кабул итте. Әлеге уңайдан Җиңү паркында тантаналы чара узды, анда Татарстан Республикасының һәм Казан шәһәренең батырлык тарихы турындагы мәгълүмат «Ватан геройлары» китабына кертелде.

Хәзерге вакытта «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан, махсус хәрби операциягә багышланган мемориаль зона төзеп, Җиңү паркы территориясен төзекләндерү концепциясен эшләү дәвам итә.

Казанның һәм Татарстан Республикасының күренекле эшлеклеләре истәлеге мәңгеләштерелде.

Мәдәният идарәсе ярдәме белән Россиянең дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасының VI чакырылыш депутаты Тимур Юрьевич Акуловка, Россия дирижеры, педагог, Казахстан ССРның халык артисты, Татарстан АССРның халык артисты, Россия Федерациясенең халык артисты Фуат Шакир улы Мансуровка, совет һәм Россия дәүләт эшлеклесе, генерал-лейтенант Николай Иванович Демидовка, совет һәм Россия кинорежиссеры, актер, сценарист, продюсер, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклесе Говорухин Станислав Сергеевичка, республиканың дәүләт санитария-эпидемиология хезмәте ветераны, Республика санитария-эпидемиология станциясе баш табибы (1965 – 1984) Якобсон Абрам Львовичка, совет партия һәм дәүләт эшлеклесе, Татарстан АССР Югары Советы Президиумы рәисе Әнвәр Бәдретдин улы Баһаутдиновка, бөек опера һәм камера җырчысы Федор Шаляпинга, Татарстанның атказанган артисты, танылган җырчы Зифа Җәмил кызы Басыйровага, Татарстан Фәннәр академиясе президенты, Татарстан Республикасының дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Мансур Хәсән улы Хәсәновка, күренекле балерина, РСФСРның, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисткасы Нинель Даут кызы Юлтыевага мемориаль такталар урнаштырылды. Музейларга йөрү туган як тарихы белән кызыксынуны арттырырга, балачактан ук танып-белү активлыгын үстерергә ярдәм итә.

Россия Федерациясе Президентының 2024 елның 23 гыйнварындагы 63 номерлы «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында»гы указы нигезендә музейларга, мәдәният һәм ял паркларына, шулай ук күргәзмәләргә бушлай йөрү өчен айга бер көн билгеләнде.

Музейлар Казанның туристик фирмалары белән дә тыгыз элемтәдә тора. Әлеге хезмәттәшлек нәтиҗәсендә Башкортстаннан, Чувашия, Мордовия, Удмуртия, Марий Эл, Пенза һәм Тамбов өлкәләре, Мәскәү, Татарстан районнары һәм башка төбәкләрдән, 50 дән артык чит илдән (Финляндия, Төркия, Германия,

Испания, Ливия, Палестина, Мисыр, Иран, Франция, Япония һ.б.) килгән кунаклар башкала музейлары белән танышты.

Киләчәктә халыкны музейлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр белән тагын да киңрәк колачлау, музейларга йөрүчеләр санын, шул исәптән халыкның социаль яктан якланмаган төркемнәре хисабына арттыру, музейларның реклама һәм PR-эшчәнлеген активлаштыру планлаштырыла. Бу муниципаль музейларны популярлаштырыга һәм музей экспонатлары белән актив рәвештә таныштырырга ярдәм итәчәк.

Халыкка күрсәтелә торган хезмәтләр спектрын киңәйтү музейларга йөрүчеләр санының һәм эшмәкәрлек эшчәнлегеннән керемнәрнең артуына китерәчәк.

Шуңа да карамастан, шәһәр бюджеты муниципаль музейларны финанслауның төп чыганагы булып тора. Бүлеп бирелә торган акчаларның төп өлеше коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә, биналарны карап тотуга һәм хезмәт хакын түләүгә юнәлдерелә.

Музейларны заманча стандартлар нигезендә мәгълүматлаштыру, офис техникасы белән җиһазландырудан тыш, кыйммәтле программалар һәм махсус техника сатып алуны күздә тоткан шактый зур финанс кертемнәре таләп итә. Бүгенге көндә музейлар алдында торган төп бурычларның берсе – халык белән эшләүдә хезмәттәшлекнең заманча формаларын куллану.

## III. Гамәлгә ашыру вакытын күрсәтеп, 1 нче ярдәмче программаның максатлары һәм бурычлары

1 нче ярдәмче программаның максаты – музей эшчәнлеген заманча мәгълүмати җәмгыять таләпләре нигезендә үстерү. Әлеге максатка ирешү өчен музей мохитенең максатчан аудиториясен киңәйтүгә юнәлтелгән чаралар комплексы үткәрү зарур.

Моның өчен, музей эшчәнлегенең төп юнәлешләрен саклаган хәлдә, музейлар белән халык арасындагы хезмәттәшлекнең яңа формаларын эзләү һәм үстерү бурычын хәл итәргә кирәк.

Бу гражданнарны мәдәни кыйммәтләргә якынайту максатыннан күргәзмәләр, лекцияләр, презентацияләр оештыру өчен шартлар тудыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыруны, аудитория белән аралашуның яңа заманча формаларын файдалануны, музейларга волонтерлар җәлеп итүне күздә тота.

Бер елда халыкның барлык категорияләре тарафыннан музейларга йөрүләр, цифрлы ресурсларга мөрәҗәгатьләр саны – әлеге бурычны хәл итүнең төп күрсәткечләре.

1 нче ярдәмче программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары исемлеге һәм чараларны финанслау 1 нче ярдәмче программага кушымтада китерелде.

1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2025-2029 еллар.

## IV. 1 нче ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 241 068,5 мең сумны тәшкил итә, шуларның 226 068,5 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 15 000,0 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән.

| Ел | Акча күләме, мең сумнарда | |
|---|---|---|
| | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | Бюджеттан тыш акчалар |
| 2025 | 45 213,7 | 3 000,0 |
| 2026 | 45 213,7 | 3 000,0 |
| 2027 | 45 213,7 | 3 000,0 |
| 2028 | 45 213,7 | 3 000,0 |
| 2029 | 45 213,7 | 3 000,0 |
| **БАРЛЫ-ГЫ** | **226 068,5** | **15 000,0** |

1 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, тиешле финанс елына һәм план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты проектын формалаштырганда, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның муниципаль заказчысы – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.

Программа чараларын гамәлгә ашыру Программа заказчы тарафыннан Программа чараларын үтәүчеләрнең барысы белән дә төзелә торган муниципаль контрактлар нигезендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына катгый рәвештә туры китереп башкарыла.

Программаның муниципаль заказчысы:

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Казан шәһәре Башкарма комитеты карарына 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра;

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлегенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы кысаларында шәһәрнең мәдәният учреждениеләре объектларында куркынычсызлыкны һәм аларның террорчылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшыра;

- ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат тапшыра.

## VI. 1 нче ярдәмче программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашырудан төп социаль-икътисади нәтиҗә мөмкин кадәр күбрәк шәһәрлеләрне һәм Казан кунакларын музей мохитенә җәлеп итүдә чагыла. Ул үз чиратында музей-белем бирү һәм социаль-мәдәни үзәкләр функцияләре булган сәнгать комплексларыннан гыйбарәт.

Кичектерелгән гамәлнең нәтиҗәлелеге:

- гражданнарда мәдәни кыйммәтләргә сакчыл караш тәрбияләүдә;

- яшьләргә эстетик һәм патриотик тәрбия бирүне үстерүдә;

- музейларның халык белән хезмәттәшлегенең яңа заманча формаларын үстерүдә;

- муниципаль музейлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын күтәрүдә чагылачак.

1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр:

- 2029 елда музейларга йөрүләр санын, 2024 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 1,2 тапкырга арттыру. Исәпләүдә Федераль статистик күзәтүнең

8-НК номерлы «Музейга килүчеләр саны – барлыгы, мең кеше» формасына тәңгәл күрсәткеч кулланыла, ул «Тармакның статистик хисаплылыгы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетта хисап чорына булган күрсәткечләр суммасыннан гыйбарәт;

- ел саен мәдәни-тарихи мирас өлкәсендә бер иҗади инициативага һәм проектка ярдәм итү;

- 2029 елда предметларның гомуми санынннан цифрланган музей предметларының чагыштырмача күләмен 56 процентка җиткерүгә ирешү;

- мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашучылар санын 2029 елга 850 кешегә кадәр арттыру;

- Казан шәһәре Музей комплексы базасында иҗади һәм социомәдәни инициативаларны гамәлгә ашыру өчен мәдәният өлкәсендә волонтерлык эшчәнлеген үстерү;

- гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар санын 2029 елга 1500 кешегә кадәр арттыру.

«Музей эшен үстерү»
1 нче ярдәмче программасына
кушымта

**«Музей эшен үстерү» 1 нче ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 1 нче ярдәмче программа чараларын финанслау**

| Төп чаралар атамасы | Башка-ручы-лар | Төп чара-ларны баш-кару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикатор-лары, үлчәү берәмлек-ләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | База 2024 | план 2025 | план 2026 | план 2027 | план 2028 | план 2029 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
| Максат: музей эшчәнлеген заманча мәгълүмати җәмгыять таләпләре нигезендә үстерү | | | | | | | | | | | | | | |
| Музей эшчәнлегенең төп юнәлешләрен саклаган хәлдә, музейлар белән халык арасындагы хезмәттәшлекнең яңа формаларын эзләү һәм үстерү | | | | | | | | | | | | | | |
| Төп чара: музейларны үстерү | | | | | | | | | | | | | | |
| Граждан-нарны мәдәни кыйммәт-ләргә җәлеп итү | Казан шәһәре Мәдәният идарәсе, музейлар | 2025-2029 | Музейларга йөрүләр саны, мең йөрү | 120,0 | 124,8 | 129,6 | 134,4 | 139,2 | 144,0 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| | | | Мәдәни-тарихи мирас өлкәсендә | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Бюд-жет, бюд-жет- | Бюд-жет, бюд-жет- | Бюд-жет, бюд-жет- | Бюд-жет, бюд-жет- | Бюд-жет, бюд-жет- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ярдәм күрсәтелгән иҗади инициатива-лар һәм проектлар саны | | | | | | | тан тыш чара-лар | тан тыш чара-лар | тан тыш чара-лар | тан тыш чара-лар | тан тыш чара-лар |
| | | | Мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программа-ларында катнашучы-лар саны, кеше | 750 | 750 | 750 | 800 | 800 | 850 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| | | | Ирекләләр эшчәнлегенн-дә катнашучы гражданнар саны, кеше | 20 | 21 | 22 | 23 | 23 | 23 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| | | | Гомум-россия гражданлык бердәмлеген ныгытуга юнәлдерел-гән чараларда | 1000 | 1100 | 1200 | 1300 | 1400 | 1500 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | катнашучы-лар саны, кеше | | | | | | | | | | | |
| Музейлар эшендә яңа мәгълүмати һәм цифрлы технология-ләрне кулланышка кертү | Казан шәһәре Мәдә-ният идарәсе, музей-лар | 2025-2029 | Музей өлкәсендә цифрлы ресурсларга мөрәҗәгать-ләр саны | 500 | 800 | 1100 | 1400 | 1700 | 2000 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| | | | Предмет-ларның гомуми саныннан цифрланган музей предмет-ларының чагыштыр-мача күләме, % | 55 | 55 | 55,5 | 55,5 | 56 | 56 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| **1 нче ярдәмче программа буенча БАРЛЫГЫ, шул исәптән** | | | | | | | | | | **48 213,7** | **48 213,7** | **48 213,7** | **48 213,7** | **48 213,7** |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына – муниципаль йөкләмә кысаларында музейларның агымдагы эшчәнлеген тәэмин итүгә | | | | | | | | | | 45 213,7 | 45 213,7 | 45 213,7 | 45 213,7 | 45 213,7 |
| бюджеттан тыш акчалар хисабына | | | | | | | | | | 3 000,0 | 3 000,0 | 3 000,0 | 3 000,0 | 3 000,0 |

Файдаланылган кыскартулар исемлеге:

бюджет – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты;

Мәдәният идарәсе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе.

«2025-2029 елларга
Казан шәһәрендә мәдәниятне
үстерү» муниципаль программасына
4 номерлы кушымта

**«Китапханә эшен үстерү»**
**2 нче ярдәмче программасы**

## I. 2 нче ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программа атамасы | «Китапханә эшен үстерү» (алга таба – 2 нче ярдәмче программа) |
| Муниципаль заказчы | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Мәдәният идарәсе) |
| 2 нче ярдәмче программаны төп эшләүче | Мәдәният идарәсе |
| 2 нче ярдәмче программаны башкаручылар | Мәдәният идарәсе, Казан шәһәренең Мәдәният идарәсе карамагындагы бюджет һәм автоном учреждениеләре |
| 2 нче ярдәмче программаның максаты | Казан шәһәрендә муниципаль китапханәләрнең халыкның барлык катламнарының мәгълүматтан иркекле файдалана алуын тәэмин итә торган заманча һәм таныла торган образын булдыру |
| 2 нче ярдәмче программаның бурычлары | Китап укуга җәлеп итү буенча яңа мәгълүмат-китапханә практикаларын гамәлгә ашыру юлы белән китапханәләрнең иҗтимагый әһәмияткә ия статусын күтәрү, халыкның мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлегенең социаль гарантияләрен тәэмин итү өчен китапханәләр фондларын актуальләштерү, шулай ук яңа мәгълүмат-китапханә сервис хезмәтләрен оештыру |
| 2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2025-2029 еллар |
| Елларга һәм чыганакларга бүлеп, 2 нче ярдәмче | 2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 910 033,5 мең сумны тәшкил итә, шуларның 909 033,5 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 1 000,0 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән. |

<table>
<tr><td rowspan="8">программаны финанслау күләме</td><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="2">Акча күләме, мең сумнарда</td></tr>
<tr><td>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</td><td>Бюджеттан тыш чаралар</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>181 806,7</td><td>200,0</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>181 806,7</td><td>200,0</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>181 806,7</td><td>200,0</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>181 806,7</td><td>200,0</td></tr>
<tr><td>2029</td><td>181 806,7</td><td>200,0</td></tr>
<tr><td>БАР-ЛЫГЫ</td><td>909 033,5</td><td>1000,0</td></tr>
<tr><td></td><td colspan="3">Искәрмә: 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>2 нче ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 2 нче ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td colspan="3">2 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- 2029 елда китапханәләргә йөрүләр санын, 2024 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 1,6 тапкырга арттырырга;<br>- китапханә фондларын тотрыклы рәвештә ел саен яңартырга;<br>- гомумроссия гражданлык бердәмлегелен ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар санын 1500 кешегә кадәр арттырырга;<br>- ел саен интеллектуаль ял итү өлкәсендәге бер иҗади инициативага һәм проектка ярдәм итәргә;<br>- мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашучылар санын 2029 елга 850 кешегә кадәр арттырырга</td></tr>
</table>

## II. 2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән 2 нче ярдәмче программа хәл итәргә тиешле мәсьәләләр исемлеге

Китапханә эшен үстерү һәм халыкка китапханә-мәгълүмат хезмәте күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте сәясәте 2019 елның 6 августындагы 65-ТРЗ номерлы «Китапханәләр һәм китапханә эше турында»гы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 16 декабрендәге 997 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» программасы, 2015 елның

17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау турында»гы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнде.

Дөньяда мәгълүмат зур тизлек белән үскән чорда һәркем файдалана алырлык китапханәләрнең әһәмияте арта һәм алгы планга һәркем файдалана алырлык китапханәнең мәгълүмат мохитен булдыру бурычы килеп баса, ә ул, билгеле бер мәгълүмат массивына гына түгел, аны тапшыруның заманча мәгълүмати технологияләренә, заманча укучыга китап укуда ярдәм итүнең һәм Казан шәһәрендә – мегаполиста яшәүчеләрне укуга җәлеп итүнең өр-яңа практикаларына да ия булырга тиеш.

Китапханә – шәһәр тормышының барлык өлкәләрен мәгълүмат белән тәэмин итү буенча җаваплылыкның шактый зур өлешен үз өстенә йөкли алырлык бердәнбер социаль институт.

Заманча китапханә сәясәте китапханәләр эшчәнлеген функциональ-эчтәлек ягыннан реконструкцияләү зарурлыгын тудыра. Ә мондый үзгәртеп кору үз чиратында китапханәне «чыгымлы» статустан муниципаль берәмлекнең иң мөһим ресурсы статусына күтәрүгә юнәлдерелгән.

Китапханәләрне модернизацияләү программасы китапханә сәясәтен 2030 елга кадәр Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең социаль-икътисади үсеш стратегиясе бурычлары системасына интеграцияләүне күздә тота. Аның төп максаты – кеше капиталына карата игътибар. Шулай ук программа муниципаль китапханәләрнең нәтиҗәле, максатчан, динамик үсешенең төп өстенлекләрен билгели.

Казан шәһәрендә яшәүчеләргә китапханә хезмәте күрсәтүне Үзәкләштерелгән китапханә системасы тәэмин итә. «Казан шәһәренең үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе составында, китапханә пунктларын да кертеп, 54 муниципаль китапханә исәпләнә, аларда стационардан тыш режимда мәгълүмат-китапханә хезмәтләре «Библиобус» мобиль китапханә комплексы тарафыннан күрсәтелә.

Хисап бирә торган 2023 елда «Казан шәһәренең үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесендә 11 088 чара үткәрелде; Үзәк китапханәдә 1 050 чара уздырылды; Үзәк балалар китапханәсендә – 2 268 чара.

2023 елда китапханә хезмәтләреннән файдаланучылар саны 197 181 кешене, китап бирүләр саны – 4 582 206 нөсхәне, китапханә фонды 2 544 215 нөсхәне тәшкил итте.

Татарстан тарафыннан шефлыкка алынган Лисичанск һәм Рубежное шәһәрләре китапханәләренә гуманитар йөк сыйфатында 300 дән артык китап тапшырылды. Китапханә хезмәтләренә булган ихтыяҗ китапханәләргә халыкның төрле төркемнәрен җәлеп итә. Хәзерге заман укучысының мәгълүматка булган ихтыяҗлары өлкәсендәге яңалык һәм төрлелек китапханәнең мәгълүмати функциясенең әһәмиятен билгели, һәм аның үсеш векторлары социаль-мәдәни таләпләргә җавап бирергә тиеш. Әлеге контекстта китапханә шәһәрнең барлык социаль-мәдәни инфраструктурасының мәгълүмат үзәгенә әверелә.

Өстенлекле юнәлешләр булып түбәндәгеләр тора:

- укуга ярдәм итүнең төрле формаларын киңәйтү, аны методик һәм методологик яктан тәэмин итүне үстерү;

- һәркем файдалана алырлык китапханәнең һәркем файдалана алырлык заманча мәгълүмат мохитен булдыру, мәгълүматны чагылдыруның яңа чараларын актив рәвештә эш практикасына кертү;

- мәгълүмат-китапханә хезмәте күрсәтүнең стационар булмаган формаларын көчәйтү;

- китапханә фондын актуальләштерү, басма документ чыганакларны цифрлаштыру;

- стратегик идарә алымнарын гамәлгә кертү, Китапханәләрне үстерү үзәген булдыру.

Соңгы елларда китапханәләр тарафыннан шәһәр киңлегенең ачык мәйданчыкларында эшләүгә юнәлдерелгән проектлар – «Әдәби ишегаллары», китап фестивальләре уңышлы тормышка ашырыла. Шәһәр поселокларында, социаль учреждениеләрдә, шәһәр чараларында халыкка стационар булмаган хезмәт күрсәтү буенча «Библиобус – мобиль китапханә» проектын гамәлгә ашыруга ихтыяҗ артты.

Укучыларга яңа әдәби әсәрләр авторлары белән танышу мөмкинлеге бирә торган «Әдәби кафе» чаралары да популярлык казанды. Китапханә эшчәнлеген модернизацияләү контекстында башкала халкына мәгълүмат-китапханә хезмәте күрсәтүне оештыруда уңышлы методология новацияләр белән проект-максатчан идарә итү чикләрендә үсәчәк.

Өлкән яшьтәге шәһәрлеләр өчен «Яшәү яме» шәһәр проекты кысаларында оештырылган «Мобиль ликбез» проекты компьютер белемен арттыруга, заманча коммуникация чараларын үзләштерүгә юнәлдерелгән.

«КаЛитКа» (Казан әдәби кафесы) социаль-мәдәни проекты әдәби тормышта истә калырлык вакыйгаларны колачлаган әдәби контент булдыруны

күздә тота һәм китап укый торган кешеләр өчен «үсеш ноктасы» булыр дип көтелә.

Ел саен башкала халкы һәм кунаклары өчен «Книга-фест», «Китапханә төне» һәм «Китапханәдә эңгер-меңгер» фестивальләре оештырыла. Аларда китап, филология һәм китап белеме, әхлакый-гражданлык, полиграфия һәм эстетик күзлектән чыгып, аерым культурологик күренеш буларак тәкъдим ителә.

Муниципаль китапханә заманча инфраструктураны күздә тота. Китапханәләрнең формалары һәм функцияләре эволюциясе мәгълүмат киңлеген эстетик һәм функциональ яктан яңарту зарурлыгына китерә. Ул тонык һәм бер типтагы китапханә учреждениеләре турындагы фикерне тамырдан үзгәртәчәк. Китапханә киңлеге архитектурасы интеллектуаль ялның төрле формаларын, шул исәптән шәхси форманы (басма һәм цифрлаштырылган текстлар, медиаресурслар белән эшләү), кызыксынулар буенча укучылар клубы кысаларында оештырылган дәрес формаларын, дискуссия һәм иҗат мәйданчыкларын булдыру мөмкинлеген күз алдында тотарга тиеш.

Югары технологияләрнең кеше эшчәнлегенең барлык өлкәләренә бик тиз үтеп керүе китапханәләрне өр-яңа технологик фундаментта кардиналь реформалауны таләп итә.

Төп бурыч – «Цифрлы китапханә» проекты кысаларында, мәгълүматның үтә күренмәлеген тәэмин итүне дә кертеп, ачык мәгълүмат мохите булдыру.

Китапханәләр челтәрен модернизацияләүне оештыру эшчәнлегенең төп максаты булып муниципаль китапханәләрнең уңай имиджын формалаштыру, китапханә киңлегенең яңа архитектурасын булдыру (ребрендинглау) тора. Ул түбәндәгеләрне күз алдында тота:

- мәгълүмат-китапханә практикаларын ачык җәмәгать киңлекләрендә (парклар, скверлар, торак шәһәр массивлары) гамәлгә кертү, һәркем файдалана алырлык китапханәләрнең имидж сәясәтен актив рәвештә үстерү;

- мәгълүмат-китапханә хезмәтләреннән максималь файдалана алуга юнәлдерелгән социомәдәни практикаларны гамәлгә ашыру, эчке һәм тышкы маркетинг;

- шәһәр социомәдәни чараларын адреслы тәэмин итү;

- яңа мәгълүмат-китапханә хезмәтләрен заманча социомәдәни өлкә базарына чыгару.

## III. Гамәлгә ашыру вакытын күрсәтеп, 2 нче ярдәмче программаның максатлары һәм бурычлары

2 нче ярдәмче программаның максаты – Казан шәһәрендә муниципаль китапханәләрнең халыкның барлык катламнарының мәгълүматтан ирекле файдалана алуын тәэмин итә торган заманча һәм таныла торган образын булдыру

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычны хәл итү зарур: китап укуга җәлеп итү буенча яңа мәгълүмат-китапханә практикаларын гамәлгә ашыру юлы белән китапханәләрнең иҗтимагый әһәмияткә ия статусын күтәрү, халыкның мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлегенең социаль гарантияләрен тәэмин итү өчен китапханәләр фондларын актуальләштерү, шулай ук яңа мәгълүмат-китапханә сервис хезмәтләрен оештыру.

Әлеге бурычны хәл итү хезмәтләрдән файдаланучыларның таләпләренә җавап бирә торган китапханә фондлары моделен булдыруны, кызыксынып укуны формалаштыруны, уку культурасын арттыруны, муниципаль китапханәләрнең мәгълүмат ресурсларын чагылдыра торган Җыелма электрон каталогны алып баруны, эшчәнлекнең стационар булмаган формаларын оештыру юлы белән шәһәр халкы өчен муниципаль китапханәләрнең мәгълүмат-китапханә ресурсларыннан максималь файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүне, белгечләрнең һөнәри компетенцияләрен, белемнәрен һәм күнекмәләрен күтәрүне күздә тота.

2 нче ярдәмче программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары исемлеге һәм чараларны финанслау 2 нче ярдәмче программага кушымтада китерелде.

2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2025-2029 еллар.

## IV. 2 нче ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 910 033,5 мең сумны тәшкил итә, шуларның 909 033,5 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 1 000,0 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән.

| Ел | Акча күләме, мең сумнарда | |
|---|---|---|
| | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | Бюджеттан тыш чаралар |
| 2025 | 181 806,7 | 200,0 |
| 2026 | 181 806,7 | 200,0 |
| 2027 | 181 806,7 | 200,0 |
| 2028 | 181 806,7 | 200,0 |
| 2029 | 181 806,7 | 200,0 |
| **БАР-ЛЫГЫ** | **909 033,5** | **1 000,0** |

Искәрмә: 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. 2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның муниципаль заказчысы – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.

Программа чараларын гамәлгә ашыру Программа заказчы тарафыннан Программа чараларын үтәүчеләрнең барысы белән дә төзелә торган муниципаль контрактлар нигезендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына катгый рәвештә туры китереп башкарыла.

Программаның муниципаль заказчысы:

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Казан шәһәре Башкарма комитеты карарына 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра;

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлегенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы кысаларында шәһәрнең мәдәният учреждениеләре объектларында куркынычсызлыкны һәм аларның террорчылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшыра;

- ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат тапшыра.

## VI. 2 нче ярдәмче программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

2 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашырудан төп социаль-икътисади нәтиҗә муниципаль китапханәләрнең социаль-мәдәни әһәмиятен реконструкцияләүдә чагылачак, бу ахыр чиктә мәгълүмат-китапханә инфраструктурасын формалаштырырга һәм китапханә ресурсларыннан максималь файдалану мөмкинлеген булдырырга, аларны алуда уңайлы шартлар тудырырга ярдәм итәчәк.

Кичектерелгән гамәлнең нәтиҗәлелеге:

- китап укучыларның – Казан халкының иҗади потенциалын активлаштыруда;

- халыкны заманча китапханә шартларында практик эшчәнлекнең төрле төрләренә җәлеп итүдә;

- башкаланы яңартуда, үстерүдә актив катнашу өчен позитив планнарны һәм мәнфәгатьләрне гамәлгә ашыру мөмкинлеге булдыруда чагылачак.

2 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- 2029 елда китапханәләргә йөрүләр санын, 2024 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 1,6 тапкырга арттырырга. Китапханәләргә йөрүләр санын исәпләгәндә, «Тармакның статистик хисаплылыгы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетта ай саен тутырыла торган белешмәләргә тәңгәл күрсәткечләр (хисап чоры өчен) суммасы файдаланыла. Әлеге белешмәләр Федераль статистик күзәтүнең 6-НК номерлы «Стационар шартларда китапханәгә йөрүләр, йөрүләр/Барлыгы», «Хезмәтләрдән читтән торып файдаланучыларның китапханәгә мөрәҗәгатьләре саны, берәмлекләр» һәм «Стационардан тыш китапханәгә йөрүләр саны, йөрүләр/Барлыгы» формасына тәңгәл;

- китапханә фондларын тотрыклы рәвештә ел саен яңартырга;

- гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар санын 1500 кешегә кадәр арттырырга;

- ел саен интеллектуаль ял итү өлкәсендәге бер иҗади инициативага һәм проектка ярдәм итәргә;

- мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашучылар санын 2029 елда 850 кешегә кадәр арттырырга.

«Китапханә эшен үстерү»
2 нче ярдәмче программасына
кушымта

**«Китапханә эшен үстерү» 2 нче ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 2 нче ярдәмче программа чараларын финанслау**

| **Төп чаралар атамасы** | **Баш-кару-чылар** | **Төп чара-лар-ны баш-кару вакы-ты** | **Ахыргы нәтиҗә-ләрне бәяләү индика-торлары, үлчәү берәмлек-ләре** | **Индикаторлар күрсәткечләре** | | | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **База 2024** | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** | **2029** | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** | **2029** |
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** | **10** | **11** | **12** | **13** | **14** | **15** |
| Максат: Казан шәһәрендә муниципаль китапханәләрнең халыкның барлык катламнарының мәгълүматтан ирекле файдалана алуын тәэмин итә торган заманча һәм танылa торган образын булдыру | | | | | | | | | | | | | | |
| Бурыч: китап укуга җәлеп итү буенча яңа мәгълүмат-китапханә практикаларын гамәлгә ашыру юлы белән китапханәләрнең иҗтимагый әһәмияткә ия статусын күтәрү, халыкның мәгълүматтан файдалана алу мөмкинлегенең социаль гарантияләрен тәэмин итү өчен китапханәләр фондларын актуальләштерү, шулай ук яңа мәгълүмат-китапханә сервис хезмәтләрен оештыру | | | | | | | | | | | | | | |
| Төп чара: китапханәләрне үстерү | | | | | | | | | | | | | | |
| Һәркем файдалана алырлык китапханәнең заманча | Казан шәһәре Мәдәният идарәсе, китап- | 2025 - 2029 | Китапханәләргә йөрүләр саны, мең йөрү | 900,0 | 1008,0 | 1116,0 | 1224,0 | 1332,0 | 1440,0 | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджет-тан тыш | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджет-тан тыш |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| мәгълүмат мохитен формалаштыру | ханәләр | | | | | | | | | | | чара-лар | | чара-лар |
| | | | Бер елга китапханә фондларының яңартылуы (китапханә фондларына алыну һәм аннан чыгарылу нисбәте), тапкыр | 2,3 | 2,3 | 2,3 | 2,3 | 2,3 | 2,3 | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар |
| | | | Гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар саны, кеше | 1000 | 1100 | 1200 | 1300 | 1400 | 1500 | Бюджет, бюджеттан тыш чара-лар | Бюджет, бюджеттан тыш чара-лар | Бюджет, бюджеттан тыш чара-лар | Бюджет, бюджеттан тыш чара-лар | Бюджет, бюджеттан тыш чара-лар |
| | | | Интеллектуаль ял өлкәсендә ярдәм күрсәтелгән иҗади | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Бюджет, бюджеттан тыш | Бюджет, бюджеттан тыш | Бюджет, бюджеттан тыш | Бюджет, бюджеттан тыш | Бюджет, бюджеттан тыш |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | инициатива лар һәм проектлар саны | | | | | | | чара-лар | чара-лар | чара-лар | чара-лар | чара-лар |
| | | | Мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашу-чылар саны | 750 | 750 | 750 | 800 | 800 | 850 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| Яңа мәгълү-мат-китапханә сервис хезмәт-ләрен оештыру | Казан шәһәре Мәдә-ният идарә-се, китап-ханә-ләр | 2025 - 2029 | Китапханә өлкәсендә цифрлы ресурслар-га мөрәҗә-гатьләр саны | 500 | 800 | 1100 | 1400 | 1700 | 2000 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| **2 нче ярдәмче программа буенча БАРЛЫГЫ, шул исәптән** | | | | | | | | | | **182 006,7** | **182 006,7** | **182 006,7** | **182 006,7** | **182 006,7** |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына | | | | | | | | | | 181 806,7 | 181 806,7 | 181 806,7 | 181 806,7 | 181 806,7 |
| бюджеттан тыш акчалар хисабына* | | | | | | | | | | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 | 200,0 |

Файдаланылган кыскартулар исемлеге:

бюджет – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты;

Мәдәният идарәсе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе.

*түләүле сервис хезмәтләре

«2025-2029 елларга
Казан шәһәрендә мәдәниятне
үстерү» муниципаль программасына
5 номерлы кушымта

**«Мәдәният-ял итү учреждениеләрен һәм концерт оешмаларын үстерү»**
**3 нче ярдәмче программасы**

## I. 3 нче ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның атамасы | «Мәдәният-ял итү учреждениеләрен һәм концерт оешмаларын үстерү» (алга таба – 3 нче ярдәмче программа) |
| Муниципаль заказчы | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Мәдәният идарәсе) |
| 3 нче ярдәмче программаны төп эшләүче | Мәдәният идарәсе |
| 3 нче ярдәмче программаны башкаручылар | Мәдәният идарәсе, Казан шәһәренең Мәдәният идарәсе карамагындагы бюджет һәм автоном учреждениеләре |
| 3 нче ярдәмче программаның максаты | Халыкка мәдәни-ял хезмәте күрсәтүнең конкурентлы системасын формалаштыру |
| 3 нче ярдәмче программаның бурычлары | Мәдәният өлкәсендә тәкъдимнәрне киңәйтү, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын, төрлелеген һәм нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән интернет-ресурсларны гамәлгә кертү юлы белән мәдәни ялны үстерүне һәм популярлаштыруны тәэмин итү |
| 3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2025-2029 еллар |
| Елларга һәм чыганакларга бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны | 3 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 6 480 169,7 мең сумны тәшкил итә, шуларның 4 677 169,7 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 1 803 000,0 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән. |

<table>
<tr><td>финанслау күләме</td><td>
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Акча күләме, мең сумнарда</th></tr>
<tr><th>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th><th>Бюджеттан тыш акчалар</th></tr>
<tr><td>2025</td><td>927 813,3</td><td>360 600,0</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>937 339,1</td><td>360 600,0</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>937 339,1</td><td>360 600,0</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>937 339,1</td><td>360 600,0</td></tr>
<tr><td>2029</td><td>937 339,1</td><td>360 600,0</td></tr>
<tr><td>БАРЛЫГЫ</td><td>4 677 169,7</td><td>1 803 000,0</td></tr>
</table>
Искәрмә: 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш</td></tr>
<tr><td>3 нче ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 3 нче ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td>3 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- 2029 елда мәдәни чараларга йөрүләр санын, 2024 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 1,6 тапкырга арттыру;<br>- ярдәм күрсәтелгән иҗади инициативалар һәм проектлар санын 2029 елда 8 данәгә кадәр арттыру (мәдәният-ял итү учреждениеләре өчен);<br>- мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашучылар санын саклап калу;<br>- гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән чараларда катнашучылар санын саклап калу;<br>- клуб берләшмәләре санын 2029 елда 740 ка кадәр арттыру;<br>- халык коллективлары санын 2024 ел күсәткеченә карата саклап калу;<br>- клуб берләшмәләрендә катнашучылар санын 2029 елда 14310 кешегә кадәр арттыру;<br>- 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге гражданнар өчен «Пушкин картасы» проекты кысаларында үткәрелгән чаралар санын 2029 елда 1250 гә кадәр арттыру (мәдәният-ял итү учреждениеләре өчен);<br>- «Тормыш яме» социаль проекты кысаларында гамәлгә ашырыла торган юнәлешләрнең санын саклап калу;<br>- 2029 елда мәдәният өлкәсендә цифрлы ресурсларга мөрәҗәгатьләр санын, 2024 ел дәрәҗәсе белән чагыштырганда, 4 тапкырга арттыру;<br>- кыргый хайваннар коллекциясен һәм үсемлекләр коллекциясен саклау;<br>- 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге гражданнар өчен «Пушкин картасы» проекты кысаларында концерт оешмалары өчен үткәрелгән чаралар санын 2029 елда 13 кә кадәр арттыру;</td></tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | - 2029 елда концерт оешмалары репертуарында яңа әсәрләр өлешен 61 гә кадәр арттыру;<br>- паркларда һәм скверларда үткәрелә торган мәдәни-ял чараларында катнашучылар санын 13650 кешегә кадәр арттыру |

## II. 3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән 3 нче ярдәмче программа хәл итәргә тиешле мәсьәләләр исемлеге

Бүген конкрет территориядә уңайлы тормыш шартлары булдыру белән бәйле проектларны гамәлгә ашыруда шәһәрләр арасындагы конкуренция актуаль бурычка әверелә. Бу, беренче чиратта, халыкның сыйфатлы мәдәни һәм күптөрле ялын, аннан барлык яшьтәге кешеләр һәм социаль төркемнәр файдалана алырлык булуын тәэмин итү. Монда төп роль Казан шәһәренең муниципаль мәдәният-ял итү учреждениеләренә һәм халыкка якынрак булган концерт оешмаларына бирелә.

**Мәдәният сарайлары һәм йортлары, мәдәният үзәкләре.**

Казанда 16 муниципаль мәдәният йорты эшли, шулай ук өч мәдәният-ял итү учреждениесе (Рок мәктәбе, «Оперение» иҗади үсеш студиясе, «Апуш» балалар татар театр студиясе) шәһәрлеләргә үз иҗади мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру мөмкинлеге бирә. Мәдәният йортлары тарафыннан тәкъдим ителә торган мәдәни хезмәтләр һәм чаралар спектры күптөрле, алар гел үзгәрештә һәм вакыт узган саен Казан халкы ихтыяҗларына күбрәк туры килә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы «2024 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәтләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында»гы карары нигезендә Казан шәһәрендә клуб тибындагы муниципаль учреждениеләр белән фактта тәэмин ителеш дәрәҗәсе норматив ихтыяҗның 25 процентын тәшкил итә.

Социомәдәни инициативаларга һәм халыкның төрле төркемнәрен үз эченә алган һәвәскәрләр иҗатына ярдәм итү максатыннан 2023 елда Казанда 737 клуб берләшмәсе үз эшчәнлеген гамәлгә ашырды, аларда барлыгы 14304 кеше исәпләнә. Шуларның 476 сы – үзешчән халык иҗаты берләшмәләре, шул исәптән 316 сы – 14 яшькә кадәргe балалар өчен, аларга 5860 кеше җәлеп ителгән.

2023 елда Казан шәһәренең мәдәният-ял итү төрендәге учреждениеләре көче белән 6396 чара уздырылды (мәдәният-ял итү чараларының гомуми санынннан 2463 е – 14 яшькә кадәргe балалар өчен).

Мәдәният-ял итү учреждениеләре ветераннарның районнардагы, шәһәр һәм республикадагы иҗтимагый советлары һәм социаль яклау органнары белән актив эш алып баралар.

Мәдәният-ял итү учреждениеләре базаларында эшләп килүче ветераннарның иҗат коллективларына һәм һәвәскәр берләшмәләренә традицион рәвештә зур игътибар бирелә. Әлеге коллективлар, район, шәһәр һәм республика концертларында даими катнашып, төрле фестивальләр һәм конкурслар лауреатлары буларак, концертлар кую һәм мәдәни-агарту юнәлешендә зур эшчәнлек алып баралар.

Ел саен ветераннар арасында уздырыла торган үзешчән башкаручыларның «Балкыш» республика фестиваленең район, шәһәр һәм республика этапларында 1000 гә якын кеше – мәдәният сарайларында һәм йортларында эшләп килүче клуб берләшмәләре әгъзалары катнаша.

Декабрь башында гадәттәгечә Халыкара инвалидлар көненә багышланган Инвалидлар декадасы билгеләп үтелә. Мәдәният йортларында һәм сарайларында сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар һәм аларның ата-аналары өчен даими нигездә төрле түгәрәкләр эшли. Әйтик, йога, шәрык биюләре, компьютер белеме, рәсем ясау, өстәл теннисы.

2022 елда Казан шәһәренең «П.И.Чайковский исемендәге 1 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә, шулай ук «Казан шәһәренең үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең 13 номерлы китапханә-филиалында комплекслы капиталь ремонт үткәрү кысаларында халыкның хәрәкәте чикле төркемнәре өчен биналарга тоткарлыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар башкарылды.

Халыкның хәрәкәте чикле төркемнәренең һәм инвалидларның муниципаль мәдәният учреждениеләренә тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен яраклаштырылган, Мәдәният идарәсе карамагында булган объектлар исемлеге:

- 1, 2, 3, 4, 5, 6, 7, 8, 10, 11, 15, 18 номерлы балалар музыка мәктәпләре;
- 1, 3, 4, 7 номерлы балалар сәнгать мәктәпләре;
- Северный, Вознесение, Мирный, Красная Горка, Кадыш, Нагорный, Отар, Константиновка торак массивларындагы мәдәният йортлары;
- Юность, Полимер, Ленин исемендәге, Сәетгалиев исемендәге һәм Тимерьюлчылар мәдәният сарайлары;
- «Мәскәү», «Сәйдәш», «Чулпан» мәдәният үзәкләре;
- башка учреждениеләр: Хәтер китабы, К.Васильев музее.

Терәк-хәрәкәт аппараты бозылган затларның 4, 6, 7, 11, 12, 13, 18, 20, 24, 37, 38, 43, 45, 47 номерлы китапханә-филиаллардан, Үзәк балалар китапханәсеннән, Үзәк китапханәдән файдалану мөмкинлеге бар.

2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеш стратегиясе кысаларында гамәлгә ашырыла торган флагман проектларның берсе – «Актив озын гомер» проекты. Шуңа бәйле рәвештә пенсионерлар өчен клуб эшен модернизацияләү мәсьәләсен хәл итү актуаль бурычка әйләнә. «Яшәү яме» социаль проекты өлкән яшьтәге кешеләргә иҗади, танып-белү һәм физик эшчәнлек белән бушлай шөгыльләнергә мөмкинлек бирә. «Яшәү яме» чаралары шәһәрнең 106 мәйданчыгында – мәдәният йортларында, китапханәләрдә, спорт объектларында, ә җәйге чорда паркларда, скверларда һәм яр буйларында уза. Проект 20 дән артык юнәлеш буенча гамәлгә ашырыла, алар арасында бигрәк тә бию, вокал, сәламәт яшәү рәвеше һәм мобиль ликбез юнәлешләре актуаль. Мәдәният учреждениеләрендә уза торган чараларга йөрү өлешендә проектның еллык күрсәткече – 150 000 визит.

Муниципаль берәмлекләрнең иҗтимагый-мәдәни киңлеген үстерү, ял итү сыйфатын һәм мәдәни байлыклардан һәркем файдалана алу мөмкинлеген арттыру бурычлары шәһәрнең парк зоналарында муниципаль мәдәният-ял итү учреждениеләре катнашында гамәлгә ашырыла торган «Мәдәни мохит» проекты тарафыннан хәл ителә.

Яңа бурычлар мәдәният учреждениеләренең кадрлар һәм финанс-икътисади сәясәтен алып баруга заманча якын килүне таләп итә. Муниципаль мәдәният учреждениеләренең бүгенге көнгә кадәр 1995 елда ук расланган нормалар (Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 1995 елның 20 апрелендәге 72 номерлы «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы системасы учреждениеләренең типлаштырылган штатларын раслау турында»гы әмере) буенча исәпләнә торган типлаштырылган штатларын яңадан карап чыгу зарур. Әлеге мәсьәлә берләштерелгән карарлар кабул итүне һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы һәм шәһәр структуралары катнашында һәрьяклап фикер алышуны таләп итә.

Республика программасы кысаларында мәдәният-ял итү учреждениеләре янәшәсендәге парклар һәм скверлар төзекләндерелде, алар массакүләм мәдәни чаралар, бәйрәмнәр, сәнгать һәм һөнәрчелек фестивальләре, иҗат активлыгының башка формаларын үткәрү өчен ачык мәйданчыклар булып хезмәт итәләр. Әмма мәдәният-ял итү учреждениеләре янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү һәм әлеге учреждениеләрнең инфраструктурасын үстерү, аларны иҗади эшчәнлекнең төрле рәвешләре белән тулыландыру бурычы якын киләчәктә дә

актуаль булып калачак.

2021 елның сентябреннән Россия Федерациясендә «Пушкин картасы» проекты старт алды. Проект кысаларында муниципаль учреждениеләр тарафыннан 2023 елда Казан шәһәрендә 2038 чара уздырылды, аларга 21,3 млн сумлык 51 меңнән артык билет сатылды.

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы чараларның «PRO.Культура.РФ» бердәм порталын булдырды, анда Казан шәһәренең 190 учреждениесе теркәлде, шуларның 51 е – Мәдәният идарәсе карамагында, 48 счетчик өстәлде.

**Концерт оешмалары.**

Казан шәһәренең концерт оешмалары составына София Гобәйдуллинаның Заманча музыка үзәге, Ля Примавера Казан камера оркестры, Казан шәһәр филармониясе керә.

Казан шәһәренең «La Primavera Казан камера оркестры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе 1989 елда оештырылды. Оркестрда 22 музыкант эшли, оркестр составы – кыллы музыка уен кораллары һәм фортепиано.

La Primavera оркестры үзенең масштаблы фестивальләре һәм уникаль проектлары белән яхшы билгеле. Алар арасында «L'arte del arco» («Искусство смычка») халыкара фестивален, Халыкара Абязов-фестивален, Татарстан Республикасының музыка мәктәпләре өчен «Звезды из завтра» проектын, «Концерт одного шедевра» концертларын атап үтәргә мөмкин. Оркестрның күп кенә уникаль проектлары ел саен гамәлгә ашырыла. Алар, тыңлаучыларга уңай хисләр бүләк итеп кенә калмый, ә бәлки мөһим социаль әһәмияткә дә ия. La Primavera Казан камера оркестры музейлар, парклар, шәһәр китапханәләре кебек мәдәният учреждениеләре белән хезмәттәшлек итә.

София Гобәйдуллинаның Заманча музыка үзәге «Яңа музыка» халыкара камера оркестры конкурсының Гран-при лауреаты һәм Россиянең әйдәп баручы музыкантлары һәм композиторлары катнашында концертлар һәм фестивальләр уза торган креатив мәйданчык булып тора. Даими рәвештә «Брависсимо», «Звуковые пространства Софии Губайдулиной», «Русский авангард в живописи и музыке» абонементлары концертлары, «Звучащий Дом Софии» музыка фестиваль-марафоны, «XXI гасырда классик гитара» халыкара фестивале, шулай ук шәһәрнең төрле мәдәни мәйданчыкларында күпсанлы концертлар, шул исәптән хәйрия концертлары һәм, яңа яшь аудиторияне җәлеп итү максатыннан, балалар һәм студентлар өчен бушлай акцияләр уздырыла.

2020 елның декабрендә Казан шәһәр филармониясенең стационар концерт мәйданчыгы – «Чулпан» мәдәният үзәге ачылды. Казан шәһәр филармониясе

эшчәнлеге татар милли мәдәниятен һәм Казан шәһәрендә, Татарстан Республикасында яшәүче этник бергәлекләрнең һәм халыкларның мәдәниятен саклауга, үстерүгә, шулай ук киләчәккә төбәлгән яңа мәдәни мирас булдыруга юнәлдерелгән.

Ай саен Казан шәһәр филармониясенең иҗат коллективлары тарафыннан 20 дән артык концерт куела, аларны 10 меңгә якын тамашачы карый.

2020 елда ЮНЕСКО эгидасы белән гамәлгә ашырыла торган яңа проект – Халыкара яшь композиторлар конкурсы старт алды.

Ля Примавера камера оркестры чыгышы ЮНЕСКОның «Мәдәният COVID-19 га каршы» проектына керде һәм ЮНЕСКОның иҗади шәһәрләре сайтында урнаштырылды. Шулай ук оркестр «Music-20» халыкара онлайн-фестивалендә катнашты.

2020 елда «Казан» бию ансамбле Татарстан Республикасының 100 бренды арасына керде.

«Казан» бию ансамбле студиясе мәктәбе укучылары Ижевск шәһәрендә узган Бөтенроссия «Италмас» фестивалендә Гран-при яулады.

**Казан зооботаника бакчасы.**

Казан зооботаника бакчасы (алга таба – Зоопарк) – Европада мондый төрдәге иң борынгы учреждениеләрнең берсе (1806 ел).

Ул Европаның зоопарклар һәм аквариумнар ассоциациясе (EAZA) хакыйкый әгъзасы, Европа һәм Азиянең зоопарклар һәм аквариумнар төбәк ассоциациясе әгъзасы (EARAZA) булып тора, Россия Фәннәр академиясенең Урал һәм Идел буе ботаника бакчалары советының Урал бүлеге составына керә, үсемлекләрне саклау буенча Халыкара ботаника бакчалары советы (BGCI) белән хезмәттәшлек итә.

Эшчәнлеге шәһәр өчен социаль әһәмияткә ия булган әлеге уникаль учреждение зоопаркларның Бөтендөнья табигатьне саклау стратегиясендә формалаштырылган дүрт мөһим функцияне гамәлгә ашыра. Алар – табигатьне саклау, фәнни тикшеренүләр, белем бирү, рекреация.

Моннан тыш, Россиядәге, якын һәм ерак чит илләрдәге 100 дән артык зоопарк белән хезмәттәшлек итә. Хайваннарның сирәк төрләрен үстерү һәм саклау буенча җиде халыкара программада катнаша.

Масштаблы төзелештән һәм реконструкциядән соң Зоопаркның яңа территориясе – «Африка. Замбези елгасы» актив рәвештә хайваннар белән тулылана. Иске территория дә реконструкциягә әзерләнә. Ул кунакларны Россия флорасы һәм фаунасы белән таныштырачак.

**Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе.**

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов карары нигезендә 2013 елдан Татарстан Республикасында рекреация зоналарын төзекләндерү буенча эшләр уңышлы гына башланып китте.

Республика программаларының максаты – гамәлдәге парк территорияләрен төзекләндерү һәм яңа уңайлы җәмәгать киңлекләре булдыру. Программа кысаларында Казан шәһәре территориясендә 52 парк яңартылды. Парклар иҗтимагый тормышның чын үзәкләренә әверелде, анда казанлыларга ял һәм мәшгульлекне оештыруның классик форматлардан алып эксперименталь театр активлыкларына кадәр булган күптөрле формалары тәкъдим ителә.

2017 елда «Җәмәгать киңлекләрен үстерү» республика программасы кысаларында социаль-мәдәни билгеләнештәге объектларны саклап калу һәм максатчан файдалану, массакүләм мәдәни чараларның, театраль-тамаша, спорт һәм бәйрәм чараларының сәнгати һәм оештыру дәрәҗәсен күтәрү, халыкка мәдәни хезмәт күрсәтүнең сыйфатын яхшырту, шулай ук шәһәр халкының массакүләм ялы өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерүне оештыру максатыннан Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе төзелде.

Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе эшчәнлеге өч төп юнәлеш буенча гамәлгә ашырыла:

1. Парк территорияләрен карап тоту һәм төзекләндерү: яшел үсентеләрнең агымдагы торышын күзәтү, территорияләрне җыештыру, коммуналь хезмәтләрнең өзлексез эшләвен тәэмин итү, территорияләрне саклау һ.б.

2. Паркларны һәм скверларны мәдәни программалаштыру: чараларның бердәм календарен алып бару; җәмәгать киңлекләрен мәдәни, спорт, белем бирү һәм күңел ачу чаралары белән сыйфатлы тулыландыру; иҗтимагый инициативалар белән эшләү һәм Казан шәһәре паркларында һәм скверларында халыкның үз-үзен тотышының гомуми культурасын арттыру.

3. Эшмәкәрлек эшчәнлегенә ярдәм итү: бизнесны паркларда һәм скверларда эшләүгә җәлеп итү, стационар булмаган сәүдә, җәмәгать туклануы һәм сервис объектларының сыйфатлы эшен тәэмин итү; парклар һәм скверлар территориясендә рөхсәтсез сәүдә итү очракларын ачыклау һәм булдырмау.

Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе эшендә төп принципларның берсе – шәһәр халкы һәм активистлар белән тыгыз элемтәдә тору. Республика программалары кысаларында Казан шәһәренең җәмәгать киңлекләре «проектлауда катнашу» принцибына нигезләнеп төзекләндерелде. Бу территорияне төзекләндерүгә техник бирем әзерләгәндә һәм

реконструкцияләүнең һәр этабы буенча фикер алышканда архитекторларның, шәһәр халкының һәм муниципаль хакимият вәкилләренең уртак эшчәнлек алып баруы дигән сүз. Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе эшендә «идарә итүдә катнашу» принцибы гамәлдә, ул шәһәрлеләрне идарә итү һәм территорияләрне үстерү процессларына җәлеп итүне күздә тота.

«Идарә итүдә катнашу» принцибы нигезендә Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе командасына ачык шәһәр конкурсы нәтиҗәсендә сайлап алынган берничә парк-менеджер керде. Әлеге конкурска 200 дән артык гариза кабул ителгән иде.

Хәзерге вакытта Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе карамагында 34 территория бар:

1) Казан шәһәренең Үзәк мәдәният һәм ял паркы;
2) Җиңү паркы;
3) Горки-Әмәт урманы;
4) «Сосновая роща» паркы («Химиклар» мәдәният йорты янында);
5) Урицкий паркы;
6) «Крылья Советов» паркы;
7) «Черек күл» паркы;
8) Лядской бакчасы;
9) Аксенов исемендәге сквер;
10) Мир урамындагы сквер (Дербышки поселогында);
11) «Казан» гаилә үзәге янындагы парк;
12) «Континент» паркы;
13) «Калейдоскоп» паркы;
14) Тинчурин скверы;
15) «Ак чәчәкләр» бульвары;
16) «Фестиваль» бульвары;
17) «Комсомолец» паркы;
18) Кабан күле яр буе;
19) Ю.Фучик урамындагы бульвар;
20) Дементьев урамындагы сквер;
21) Комсомол күле пляжы;
22) Аккош күле пляжы;
23) Сәетгалиев мәдәният йорты янындагы парк;
24) Казансу елгасы яр буе (ике участок);
25) «Дубрава» урман паркы янындагы керү мәйданы;
26) «Әкият» курчак театры янындагы парк;

27) «Салават Күпере» торак комплексы янындагы парк;

28) Ленин бакчасы;

29) «Акчарлак күле» паркы;

30) Татарстан Республикасында төзелеш тармагы оешуның 100 еллыгы скверы;

31) Зур Зәңгәр күл янындагы территория;

32) «Светлая долина» паркы;

33) Балыкчы бакчасы;

34) «Весна» торак комплексы янындагы парк.

Шәһәр парклары һәм скверлары казанлыларның һәм туристларның яраткан ял итү урыны булып тора. Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясенең төп бурычларыннан берсе – парк территорияләрен кызыклы чаралар белән баету, аларда заманча һәм кирәкле социомәдәни мохит булдыру.

Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе алып барган эшчәнек нәтиҗәсендә җәмәгать урыннары казанлыларны һәм башкала кунакларын җәлеп итү урынына әвереләчәк, шулай ук алар уңайлы шәһәр мохитен формалаштыруны һәм аның мәдәни эчтәлеген яхшыртуны дәвам итәчәкләр.

## III. Гамәлгә ашыру вакытын күрсәтеп, 3 нче ярдәмче программаның максатлары һәм бурычлары

Мәдәният-ял итү учреждениеләрен һәм концерт оешмаларын алга таба үстерү өчен халыкка мәдәни-ял хезмәте күрсәтүнең конкурентлы системасын формалаштыру зарур.

Әлеге максатны гамәлгә ашыру өчен түбәндәге бурычны хәл итү зарур – мәдәният өлкәсендә тәкъдимнәрне киңәйтү, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын, төрлелеген һәм нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән интернет-ресурсларны гамәлгә кертү юлы белән мәдәни ялны үстерүне һәм популярлаштыруны тәэмин итү.

Әлеге бурычны хәл итү иҗади үзешчән коллективлар, һәвәскәрләр берләшмәләре, түгәрәкләр эшчәнлеген оештыру аша иҗади инициативаларга ярдәм итүнең креатив-кластер системасын формалаштыру һәм халыкның ялын оештыру, мәдәни-күңел ачу хезмәтләре күрсәтү, шәһәрнең музыкаль мәдәниятен үстерү һәм трансляцияләү өчен репертуар концерт программаларын булдыру һәм оештыру, төбәкара һәм халыкара файдалы хезмәттәшлекне үстерү өчен гастроль-мәдәни эшчәнлек оештыру, башкару сәнгате өлкәсендә, шул исәптән балалар һәм яшүсмерләр аудиториясенә юнәлдерелгән, социомәдәни

проектларга булышлык итү, хайваннарның сирәк очрый торган төрләренең генофондын өйрәнү һәм күргәзмәгә кую, үсемлекләр коллекциясен өйрәнү һәм күргәзмәгә кую, халыкның экологик культурасын үстерү, халыкка экскурсия хезмәте күрсәтү күләмен арттыру, шәһәр халкын җәмәгать киңлекләрендә актив ял итүгә җәлеп итү максатыннан паркларда һәм скверларда массакүләм мәдәни чаралар оештыру буенча чаралар комплексын үткәрүне күздә тота.

Әлеге бурычны хәл итүнең төп күрсәткечләре – барлык яшь категорияләре өчен чаралар оештыру, мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрне цифрлаштыру һәм мәгълүмат киңлеге формалаштыру.

3 нче ярдәмче программаның төп чаралары нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары исемлеге һәм чараларны финанслау 3 нче ярдәмче программага кушымтада китерелде.

3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2025-2029 еллар.

## IV. 3 нче ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

3 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 6 480 169,7 мең сумны тәшкил итә, шуларның 4 677 169,7 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 1 803 000,0 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән.

| Ел | Акча күләме, мең сумнарда | |
|---|---|---|
| | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | Бюджеттан тыш акчалар |
| 2025 | 927 813,3 | 360 600,0 |
| 2026 | 937 339,1 | 360 600,0 |
| 2027 | 937 339,1 | 360 600,0 |
| 2028 | 937 339,1 | 360 600,0 |
| 2029 | 937 339,1 | 360 600,0 |
| **БАРЛЫГЫ** | **4 677 169,7** | **1 803 000,0** |

Искәрмә: 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. 3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның муниципаль заказчысы – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.

Программа чараларын гамәлгә ашыру Программа заказчы тарафыннан Программа чараларын үтәүчеләрнең барысы белән дә төзелә торган муниципаль контрактлар нигезендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына катгый рәвештә туры китереп башкарыла.

Программаның муниципаль заказчысы:

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Казан шәһәре Башкарма комитеты карарына 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра;

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлегенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы кысаларында шәһәрнең мәдәният учреждениеләре объектларында куркынычсызлыкны һәм аларның террорчылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшыра;

- ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәләлегe турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат тапшыра.

## VI. 3 нче ярдәмче программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашырудан төп социаль-икътисади нәтиҗә Казан халкы өчен мәдәни-ял хезмәтләреннән һәм чараларыннан файдалана алу мөмкинлеген, аларның иҗади инициативаларын максималь рәвештә гамәлгә ашыруны тәэмин итүне күздә тота.

Кичектерелгән гамәлнең нәтиҗәлелеге:

- Казан халкы өчен мәдәният өлкәсендәге тәкъдимнәрне камилләштерүдә;

- мәдәният йортлары һәм парк территорияләре инфраструктурасын үстерүдә;

- «Казанның мәдәният үзәкләре» брендын үстерүдә;

- концерт оешмаларының фестиваль һәм гастроль эшчәнлеген киңәйтүдә;

- җәмәгать киңлекләрен сыйфатлы мәдәни сервислар белән тулыландыруда;

- мәдәният өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрне цифрлаштыруда һәм мәгълүмат киңлеген формалаштыруда чагылачак.

3 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге максатчан индикаторларга һәм күрсәткечләргә фактта ирешү дәрәҗәсе буларак бәяләнә.

3 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- 2029 елда мәдәни чараларга йөрүләр санын, 2024 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 1,6 тапкырга арттыру. Мәдәният-ял итү тибындагы учреждениеләрнең һәм башка оешмаларның массакүләм мәдәни чараларына йөрүләр санын исәпләгәндә, «Чараларга йөрүләр, кеше» киселешендә Федераль статистик күзәтүнең 7-НК номерлы «Массакүләм мәдәни чаралар, барлыгы» формасына тәңгәл күрсәткеч файдаланыла. Әлеге күрсәткеч шулай ук «Тармакның статистик хисаплылыгы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетта ай саен тутырыла торган белешмәләргә туры килә. Концерт оешмалары өчен исәпләүдә Федераль статистик күзәтүнең 12-НК номерлы, шулай ук «Күргәзмәләргә, лекцияләргә, осталык дәресләренә һәм ачык репетицияләргә йөрүләр саны» формасына тәңгәл «Россия Федерациясенең үз субъекты чикләрендәге барлык концертлар» киселешендә «Тамашачылар саны: Барлыгы» һәм «Россия Федерациясендә барлык концертлар» киселешендә «Концерт оешмасының виртуаль концерт залларындагы чараларда булган тамашачылар саны, мең кеше» күрсәткечләре суммасы файдаланыла. Әлеге күрсәткеч шулай ук «Тармакның статистик хисаплылыгы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетта ай саен тутырыла торган белешмәләргә туры килә. Зоопарк өчен исәпләүдә Федераль статистик күзәтүнең 14-НК номерлы «Йөрүләр саны – барлыгы» һәм «Лекцияләрдә тыңлаучылар саны, кеше» формасына тәңгәл күрсәткечләр суммасы файдаланыла. Әлеге күрсәткеч шулай ук «Тармакның статистик хисаплылыгы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасындагы шәхси кабинетта ай саен тутырыла торган белешмәләргә туры килә;

- ярдәм күрсәтелгән иҗади инициативалар һәм проектлар санын 2029 елда 8 данәгә кадәр арттыру (мәдәният-ял итү учреждениеләре өчен);

- мәктәп укучылары өчен мәдәни-агарту программаларында катнашучылар санын саклап калу;

- гомумроссия гражданлык бердәмлеген ныгытуга юнәлдерелгән

чараларда катнашучылар санын саклап калу;

- клуб берләшмәләре санын 2029 елда 740 ка кадәр арттыру;

- халык коллективлары санын 2024 ел күсәткеченә карата саклап калу;

- клуб берләшмәләрендә катнашучылар санын 2029 елда 14310 кешегә кадәр арттыру;

- 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге гражданнар өчен «Пушкин картасы» проекты кысаларында үткәрелгән чаралар санын 2029 елда 1250 гә кадәр арттыру (мәдәният-ял итү учреждениеләре өчен);

- «Тормыш яме» социаль проекты кысаларында гамәлгә ашырыла торган юнәлешләрнең санын саклап калу;

- 2029 елда мәдәният-ял итү учреждениеләре өчен мәдәният өлкәсендә цифрлы ресурсларга мөрәҗәгатьләр санын, 2024 ел дәрәҗәсе белән чагыштырганда, 4 тапкырга арттыру;

- кыргый хайваннар коллекциясен һәм үсемлекләр коллекциясен саклау;

- 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге гражданнар өчен «Пушкин картасы» проекты кысаларында концерт оешмалары өчен үткәрелгән чаралар санын 2029 елда 13 кә кадәр арттыру;

- 2029 елда концерт оешмалары репертуарында яңа әсәрләр өлешен 61 гә кадәр арттыру;

- паркларда һәм скверларда үткәрелә торган мәдәни-ял чараларында катнашучылар санын 13650 кешегә кадәр арттыру.

«Мәдәният-ял итү учреждениеләрен
һәм концерт оешмаларын үстерү»
3 нче ярдәмче программасына
кушымта

**«Мәдәният-ял итү учреждениеләрен һәм концерт оешмаларын үстерү» 3 нче ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 3 нче ярдәмче программа чараларын финанслау**

| **Төп чаралар атамасы** | **Башкаручылар** | **Төп чараларны башкару вакыты** | **Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре** | **Индикаторлар күрсәткечләре** | | | | | | **Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда** | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | **База 2024** | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** | **2029** | **2025** | **2026** | **2027** | **2028** | **2029** |
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** | **10** | **11** | **12** | **13** | **14** | **15** |
| Максат: халыкка мәдәни-ял хезмәте күрсәтүнең конкурентлы системасын формалаштыру | | | | | | | | | | | | | | |
| Бурыч: мәдәният өлкәсендә тәкъдимнәрне киңәйтү, хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын, төрлелеген һәм нәтиҗәлелеген арттыру, шул исәптән интернет-ресурсларны гамәлгә кертү юлы белән мәдәни ялны үстерүне һәм популярлаштыруны тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | |
| Төп чара: мәдәният-ял итү учреждениеләрен үстерү | | | | | | | | | | | | | | |
| Мәдәният-ял итү учреждениеләре базасында чаралар оештыру | Мәдәният идарәсе, мәдәният-ял итү | 2025-2029 | Мәдәни-масса-күләм чараларга йөрүләр саны, мең кеше | 1200,0 | 1344,0 | 1488,0 | 1632,0 | 1776,0 | 1920,0 | Бюджет, бюджеттан тыш чара- | Бюджет, бюджеттан тыш чара- | Бюджет, бюджеттан тыш чара- | Бюджет, бюджеттан тыш чара- | Бюджет, бюджеттан тыш чара- |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | учреж-дение-ләре | | | | | | | | | лар | лар | лар | лар | лар |
| | Мәдә-ният идарә-се, мәдә-ният-ял итү учреж-дение-ләре, зоо-парк, парк-лар һәм сквер-лар | 2025-2029 | Ярдәм күрсәтел-гән иҗади инициа-тивалар һәм проектлар саны, берәмлек | 6 | 6 | 7 | 7 | 8 | 8 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чар-алар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| | Мәдә-ният идарә-се, мәдә-ният-ял итү учреж-дениел әре, зоо- | 2025-2029 | Мәктәп укучы-лары өчен мәдәни-агарту програм-маларын-да катнашу-чылар саны, | 100000 | 100000 | 100000 | 100000 | 100000 | 100000 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | парк, парк-лар һәм сквер-лар | | кеше | | | | | | | | | | | |
| | Мәдә-ният идарә-се, мәдә-нят-ял итү учреж-дение-ләре, зоо-парк, парк-лар һәм сквер-лар | | Гомум-россия граждан-лык бердәм-леген ныгытуга юнәлдер-елгән чараларда катнашу-чылар саны, кеше | 50000 | 50000 | 50000 | 50000 | 50000 | 50000 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| Клуб тибындагы мәдәният учрежде-ниеләренең булган челтәрен саклау һәм үстерү | Мәдә-ният идарә-се, мәдә-нят-ял итү учреж-дение- | 2025-2029 | Клуб берләш-мәләре саны, барлыгы, берәмлек | 737 | 738 | 738 | 739 | 739 | 740 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| | | | 2023 елга | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Бюд- | Бюд- | Бюд- | Бюд- | Бюд- |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | ләре | | карата халык коллек тивлары санының тотрык-лылыгы (сакла-нуы), % | | | | | | | жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| | | | Клуб берләш-мәләрен-дә барлык катнашу-чылар саны, кеше | 14304 | 14305 | 14306 | 14307 | 14308 | 14310 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| Граждан-нарның мәдәни, белем бирү һәм ял чаралар-ында катнашу мөмкин-лекләрен киңәйтү | Мәдә-ният идарә-се, мәдә-нherият-ял итү учреж-дение-ләре | 2025-2029 | 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге граждан-нар өчен «Пушкин картасы» проекты кыса-ларында үткәрел-гән чаралар саны, берәмлек | 1000 | 1050 | 1100 | 1150 | 1200 | 1250 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мәдәният идарәсе, мәдәният-ял итү учреждениеләре | | «Тормыш яме» социаль проекты кысаларында гамәлгә ашырыла торган юнәлешләр саны (пенсия яшендәге граждан-нар өчен), берәмлек | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | 12 | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар |
| Мәдәният-ял итү өлкәсендәге хезмәтләрне цифрлаштыру | Мәдәният идарәсе, мәдәният-ял итү учреждениеләре, зоопарк, парклар һәм сквер- | 2025-2029 | Мәдәният өлкәсендә цифрлы ресурсларга мөрәҗәгатьләр саны, мең мөрәҗәгать | 3,0 | 4,8 | 6,6 | 8,4 | 10,2 | 12,0 | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | лар | | | | | | | | | | | | | |
| Сирәк очрый торган хайван төрләренең генофондын өйрәнү һәм күргәзмәгә кую | Мәдәният идарәсе, зоопарк | 2025-2029 | Кыргый хайваннар коллекциясен саклау, экземпляр | 4539 | 4539 | 4539 | 4539 | 4539 | 4539 | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар |
| Үсемлекләр коллекциясен өйрәнү һәм күргәзмәгә кую | Мәдәният идарәсе, зоопарк | 2025-2029 | Үсемлекләр коллекциясен саклау, экземпляр | 4020 | 4020 | 4020 | 4020 | 4020 | 4020 | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар |
| Зоопаркта халыкка экскурсия хезмәте күрсәтүне арттыру | Мәдәният идарәсе, зоопарк | 2025-2029 | Бер елга зоопаркка йөрүләр саны, мең йөрү | 570,0 | 592,8 | 615,6 | 638,4 | 661,2 | 684,0 | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар |
| Шәһәр халкын шәһәрнең | Мәдәният идарә- | 2025-2029 | Бер елга паркларга һәм | 1000,0 | 1100,0 | 1200,0 | 1300,0 | 1400,0 | 1500,0 | Бюджет, бюд- | Бюджет, бюд- | Бюджет, бюд- | Бюджет, бюд- | Бюджет, бюд- |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| җәмәгать киңлек-ләрендә актив ялга җәлеп итү өчен паркларда һәм скверларда массакүләм мәдәни чаралар оештыру | се, парк-лар һәм сквер-лар | | скверлар-га йөрү саны, мең йөрү | | | | | | | жет-тан тыш чара-лар | жет-тан тыш чара-лар | жет-тан тыш чара-лар | жет-тан тыш чара-лар | жет-тан тыш чара-лар |
| | Мәдә-ният идарә-се, парк-лар һәм сквер-лар | 2025-2029 | Парклар-дагы һәм скверлар-дагы мәдәни-ял чара-ларында катнашу-чылар саны, кеше | 13600 | 13610 | 13620 | 13630 | 13640 | 13650 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| Төп чара: концерт оешмаларын үстерү | | | | | | | | | | | | | | |
| Академик музыка өлкәсендә концерт эшчән-леген үстерү | Мәдә-ният идарә-се, кон-церт оеш-малары | 2025-2029 | Концерт чара-ларына йөрүләр саны, мең йөрү | 500,0 | 540,0 | 580,0 | 620,0 | 660,0 | 700,0 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| | Мәдә-ният идарә-се, кон-церт | 2025-2029 | Ярдәм күрсәтел-гән иҗади инициа-тивалар һәм | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | оеш-малары | | проектлар саны, берәмлек | | | | | | | чара-лар | чара-лар | чара-лар | чара-лар | чара-лар |
| | Мәдә-ният идарә-се, кон-церт оеш-малары | 2025-2029 | Мәктәп укучы-лары өчен мәдәни-агарту програм-маларын-да катнашу-чылар саны, кеше | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 | 1000 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| | Мәдә-ният идарә-се, кон-церт оеш-малары | | Гомум-россия граждан-лык бердәм-леген ныгытуга юнәл-дерелгән чараларда катнашу-чылар саны, кеше | 50000 | 50000 | 50000 | 50000 | 50000 | 50000 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Коллек-тивлар һәм солист-вокалист-лар репертуа-рын яңарту, шул исәптән милли компо-нентны исәпкә алып | Мәдә-ният идарә-се, кон-церт оеш-малары | 2025-2029 | Концерт оешма-лары реперту-арында яңа әсәрләр өлеше, % | 59 | 60 | 60 | 60 | 61 | 61 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| Концерт академик музыкасы аудитория-сен киңәйтү | | | 14 яшьтән 22 яшькә кадәрге граждан-нар өчен «Пушкин картасы» проекты кыса-ларында үткәрел-гән чаралар саны, берәмлек | 10 | 11 | 12 | 12 | 13 | 13 | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жет-тан тыш чара-лар |
| Концерт эшчәнлеге | Мәдә-ният | 2025-2029 | Мәдәният өлкәсендә | 2,0 | 3,2 | 4,4 | 5,6 | 6,8 | 8 | Бюд-жет, | Бюд-жет, | Бюд-жет, | Бюд-жет, | Бюд-жет, |

| | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| өлкәсендә мәгълүмат киңлеген формалаштыру | идарәсе, концерт оешмалары | | цифрлы ресурсларга мөрәҗәгатьләр саны, мең мөрәҗәгать | | | | | | | бюджеттан тыш чаралар | бюджеттан тыш чаралар | бюджеттан тыш чаралар | бюджеттан тыш чаралар | бюджеттан тыш чаралар |
| **3 нче ярдәмче программа буенча барлыгы, шул исәптән** | | | | | | | | | | **1 288 413,3** | **1 297 939,1** | **1 297 939,1** | **1 297 939,1** | **1 297 939,1** |
| Еллар һәм чыганаклар буенча финанслау күләмнәре | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | | | | | | | | | 927 813,3 | 937 339,1 | 937 339,1 | 937 339,1 | 937 339,1 |
| | Бюджеттан тыш чаралар | | | | | | | | | 360 600,0 | 360 600,0 | 360 600,0 | 360 600,0 | 360 600,0 |

Файдаланылган кыскартулар исемлеге:

бюджет – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты;

Мәдәният идарәсе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе;

концерт оешмалары (3 учреждение) – Казан шәһәренең «La Primavera Казан камера оркестры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе; Казан шәһәренең «София Гобәйдуллина исемендәге Заманча музыка үзәге» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе; Казан шәһәр филармониясе.

«2025-2029 елларга
Казан шәһәрендә мәдәниятне
үстерү» муниципаль программасына
6 номерлы кушымта

**«Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре системасын үстерү»**
**4 нче ярдәмче программасы**

## I. 4 нче ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның атамасы | «Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре системасын үстерү» (алга таба – 4 нче ярдәмче программа) |
| Муниципаль заказчы | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Мәдәният идарәсе) |
| 4 нче ярдәмче программаны төп эшләүче | Мәдәният идарәсе |
| 4 нче ярдәмче программаны башкаручылар | Мәдәният идарәсе, Казан шәһәренең Мәдәният идарәсе карамагындагы бюджет һәм автоном учреждениеләре |
| 4 нче ярдәмче программаның максаты | Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре системасын саклау, ныгыту һәм үстерү |
| 4 нче ярдәмче программаның бурычлары | Балалар сәнгать мәктәпләрендә белем бирү буенча сыйфатлы хезмәтләр күрсәтү өчен шартлар булдыруны тәэмин итү, талантлы яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү, үсеп килүче буынга уңышлы социальләшү һәм иҗади яктан нәтиҗәле үсеш өчен мөмкинлекләр тудыру |
| 4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты | 2025-2029 еллар |
| Елларга һәм чыганакларга бүлеп, 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме | 4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 3 663 745,4 мең сумны тәшкил итә, шуларның 3 477 495,4 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 186 250,0 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән.<br>**Ел** — **Акча күләме, мең сумнарда** |

<table>
<tr>
<td></td>
<td>
<table>
<tr><th></th><th>Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th><th>Бюджеттан тыш чаралар</th></tr>
<tr><td>2025</td><td>692 923,8</td><td>37 250,0</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>696 142,9</td><td>37 250,0</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>696 142,9</td><td>37 250,0</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>696 142,9</td><td>37 250,0</td></tr>
<tr><td>2029</td><td>696 142,9</td><td>37 250,0</td></tr>
<tr><td>БАР-<br>ЛЫГЫ</td><td>3 477 495,4</td><td>186 250,0</td></tr>
</table>
Искәрмә: 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>4 нче ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 4 нче ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td>
<td>4 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>- 2029 елда сәнгать төрләре буенча балалар сәнгать мәктәпләре тарафыннан уздырыла торган мәдәни чараларга йөрүләр санын, 2024 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 1,6 тапкырга арттыру;<br>- бюджет нигезендә белем алучыларның гомуми саныннан барлык дәрәҗәдәге фестиваль-конкурслар хәрәкәтенә җәлеп ителгән балалар өлешен 2029 елда 77 процентка кадәр арттыру;<br>- ел саен белем бирү өлкәсендәге бер иҗади инициативага һәм проектка ярдәм итү;<br>- балалар сәнгать мәктәбендә белем алуга бер бюджет урынына кандидатлар (кабул ителүчеләр һәм кабул ителгәннәр нисбәте) санын 2024 ел дәрәҗәсендә саклап калу;<br>- балалар сәнгать мәктәпләрен тәмамлап, мәдәният һәм сәнгать буенча урта һәм югары уку йортларында профильле белем алуны дәвам иткән балалар өлешен 2024 ел дәрәҗәсендә саклап калу;<br>- бюджет нигезендә белем алучыларның гомуми саныннан белем бирү оешмасында сәнгать өлкәсендәге өстәмә башлангыч һөнәри программаларны бюджет нигезендә үзләштерүче балалар өлешен 2029 елда 80 процентка арттыру;<br>- бюджет нигезендә белем алучыларның гомуми саныннан бөтенроссия һәм халыкара чараларда җиңгән һәм призлы урыннар яулаган балалар өлешен 2029 елда 50,5 процентка кадәр арттыру;<br>- 18 яшькә кадәр белем алучылар (түләүле нигездә) санын 2029 елда 4010 кешегә кадәр арттыру;</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | - бюджет нигезендә белем алучыларның гомуми контингентыннан җыелма массакүләм балалар коллективларына җәлеп ителгән балалар өлешен саклап калу;<br>- укытучыларның гомуми саныннан һөнәри осталык конкурсларында җиңгән һәм призлы урыннар яулаган, шулай ук төрле премияләргә лаек булган һәм грантлар откан педагоглар санын 2029 елда 410 кешегә кадәр арттыру;<br>- янгынга каршы куркынычсызлыкны арттыру һәм кешеләр була торган урыннарда шартларны яхшырту буенча чаралар үткәрелә торган учреждениеләр өлешен 2029 елда 83 процентка кадәр арттыру;<br>- муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләренең гомуми саныннан энергияне сак тоту җайланмалары белән җиһазландырылган муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләре өлешен 2029 елда 82 процентка кадәр арттыру |

## II. 4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән 4 нче ярдәмче программа хәл итәргә тиешле мәсьәләләр исемлеге

Казан бүген иҗади белем бирү үзәкләренең берсе булып санала. Белем бирү сыйфаты музыка, сәнгать, театр, хореография училищеларының югары квалификацияле профессорлар һәм укытучылар составы белән тәэмин ителә. Башкалада Казан дәүләт мәдәният институты, В.И.Суриков исемендәге Мәскәү дәүләт академия сәнгать институты филиалы эшли. Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе илнең иң яхшы музыкаль вузлары арасына керә.

Казанда мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә традицион өч баскычлы белем бирү системасы уңышлы эшләп килә, ул булачак мәдәният һәм сәнгать белгечләренә өзлексез һөнәри белем бирүне тәэмин итә. Ел саен чыгарылыш сыйныф укучыларының 10 проценты профильле урта һөнәри һәм югары уку йортларына укырга керә.

Мәдәният идарәсе 25 балалар сәнгать мәктәбе (10 музыка, 8 сәнгать, 7 рәсем сәнгате мәктәбе) эшен координацияли. Бүген 6 яшьтән 15 яшькә кадәрге һәр өченче бала Казан шәһәренең музыка яки сәнгать мәктәбендә белем ала.

2022/2023 уку елында балалар сәнгать мәктәпләрендә белем алучылар халыкара, бөтенроссия һәм төбәкара, республика һәм шәһәр конкурсларында катнаштылар. 7000 гә якын бала лауреат һәм дипломант исемнәрен алды.

«Бакиров исемендәге 6 номерлы балалар музыка мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе укучысы Крайнова Амелия «Яңа

исемнәр» хәйрия фонды стипендиаты булды. Әлеге проект Россиянең халык артисты Денис Мацуев патронажында уза.

15 бала Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясенә лаек булды. Конкурста 25 мәктәптән 80 укучы катнашты, жюри составына Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең, Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятенең, Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесының иң яхшы педагоглары, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе Рәссамнар берлеге әгъзалары керде.

Ел саен сәнгать мәктәпләренең иң яхшы укытучыларына К.Васильев исемендәге премия тапшырыла. 2023 елда жюри ачык дәресләрне дистанцион форматта карады. Җиңүчеләр булып «4 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе педагогы Мерзлякова Валерия Олеговна һәм «10 номерлы балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе педагогы Гәрәева Фәридә Фәрзетдин кызы танылды.

Сәнгать мәктәпләрендә белем алучы балаларның эшләре шәһәр чаралары кысаларында оештырылган күргәзмәләрдә күрсәтелде.

Яшьләр симфоник оркестры, Симфоджаз-оркестр, Тынлы уен кораллары оркестры, Халык уен кораллары оркестры, Җыелма хор, Гитарачылар җыелма ансамбле кебек балалар җыелма коллективларын үстерү буенча эшчәнлек дәвам итә. Коллективлар шәһәр күләмендә уздырыла торган эре чараларда катнашалар, шулай ук югары һөнәри казанышлары белән уртаклашалар.

Д.И.Железнов җитәкчелегендәге малайлар капелласы да, төрле чараларда, концертларда, конкурсларда чыгыш ясап, шәһәрнең иҗади тормышында актив катнаша.

2023 елда Казан шәһәренең сәнгать өлкәсендә өстәмә белем бирү буенча эш тәҗрибәсе белән Россиянең халык артисты В.А.Гергиев җитәкчелегендәге Мариин театры делегациясе, шулай ук Россия Федерациясе Оборона министрлыгының Үзәк хәрби оркестры делегациясе танышты.

## III. Гамәлгә ашыру вакытын күрсәтеп, 4 нче ярдәмче программаның максатлары һәм бурычлары

4 ярдәмче программаның максаты: сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре системасын саклау, ныгыту һәм үстерү.

Максатка ирешү өчен түбәндәге бурычны хәл итү зарур: балалар сәнгать мәктәпләрендә белем бирү буенча сыйфатлы хезмәтләр күрсәтү өчен шартлар булдыруны тәэмин итү, талантлы яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү, үсеп килүче буынга уңышлы социальләшү һәм иҗади яктан нәтиҗәле үсеш өчен мөмкинлекләр тудыру.

4 нче ярдәмче программаның максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм чараларын финанслау 4 нче ярдәмче программага кушымтада китерелде.

4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты – 2025-2029 еллар.

## IV. 4 нче ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итү

4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 3 663 745,4 мең сумны тәшкил итә, шуларның 3 477 495,4 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 186 250,0 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән.

| Ел | Акча күләме, мең сумнарда | |
|---|---|---|
| | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | Бюджеттан тыш чаралар |
| 2025 | 692 923,8 | 37 250,0 |
| 2026 | 696 142,9 | 37 250,0 |
| 2027 | 696 142,9 | 37 250,0 |
| 2028 | 696 142,9 | 37 250,0 |
| 2029 | 696 142,9 | 37 250,0 |
| **БАРЛЫГЫ** | **3 477 495,4** | **186 250,0** |

4 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

## V. 4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы

Программаның муниципаль заказчысы – «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе.

Программа чараларын гамәлгә ашыру Программа заказчы тарафыннан Программа чараларын үтәүчеләрнең барысы белән дә төзелә торган муниципаль контрактлар нигезендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына катгый рәвештә туры китереп башкарыла.

Программаның муниципаль заказчысы:

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә Казан шәһәре Башкарма комитеты карарына 2 номерлы кушымтада китерелгән форма буенча «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра;

- квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның егерменче көненә кадәр Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә программаларны координацияләү бүлегенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасы кысаларында шәһәрнең мәдәният учреждениеләре объектларында куркынычсызлыкны һәм аларның террорчылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында мәгълүмат тапшыра;

- ел саен, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппаратының икътисади үсеш комитетына һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Финанс идарәсенә «2025-2029 елларга Казан шәһәрендә мәдәниятне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру, шулай ук финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында статистик, белешмә һәм аналитик мәгълүмат тапшыра.

## VI. 4 нче ярдәмче программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелеген бәяләү

4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашырудан төп социаль-икътисади нәтиҗә балалар сәнгать мәктәпләренең, өстәмә белем бирү педагогы һөнәренең һәм балалар сәнгать мәктәбендә белем алучының социаль абруен күтәрүне күздә тота.

Кичектерелгән гамәлнең нәтиҗәлелеге:

- бюджет нигезендә белем алучылар контингентын саклап калуда;

- балалар сәнгать мәктәпләрендә Россия законнары белән гарантияләнгән бушлай белем бирүдә чагылачак.

4 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

- 2029 елда сәнгать төрләре буенча балалар сәнгать мәктәпләре тарафыннан уздырыла торган мәдәни чараларга йөрүләр санын, 2024 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 1,6 тапкырга арттыру;

- бюджет нигезендә белем алучыларның гомуми санынннан барлык дәрәҗәдәге фестиваль-конкурслар хәрәкәтенә җәлеп ителгән балалар өлешен 2029 елда 77 процентка кадәр арттыру;

- ел саен белем бирү өлкәсендәге бер иҗади инициативага һәм проектка ярдәм итү;

- балалар сәнгать мәктәбендә белем алуга бер бюджет урынына кандидатлар (кабул ителүчеләр һәм кабул ителгәннәр нисбәте) санын 2024 ел дәрәҗәсендә саклап калу;

- балалар сәнгать мәктәпләрен тәмамлап, мәдәният һәм сәнгать буенча урта һәм югары уку йортларында профильле белем алуны дәвам иткән балалар өлешен 2024 ел дәрәҗәсендә саклап калу;

- бюджет нигезендә белем алучыларның гомуми санынннан белем бирү оешмасында сәнгать өлкәсендәге өстәмә башлангыч һөнәри программаларны бюджет нигезендә үзләштерүче балалар өлешен 2029 елда 80 процентка арттыру;

- бюджет нигезендә белем алучыларның гомуми санынннан бөтенроссия һәм халыкара чараларда җиңгән һәм призлы урыннар яулаган балалар өлешен 2029 елда 50,5 процентка кадәр арттыру;

- 18 яшькә кадәр белем алучылар (түләүле нигездә) санын 2029 елда 4010 кешегә кадәр арттыру;

- бюджет нигезендә белем алучыларның гомуми контингентыннан җыелма массакүләм балалар коллективларына җәлеп ителгән балалар өлешен саклап калу;

- укытучыларның гомуми санынннан һөнәри осталык конкурсларында җиңгән һәм призлы урыннар яулаган, шулай ук төрле премияләргә лаек булган һәм грантлар откан педагоглар санын 2029 елда 410 кешегә кадәр арттыру;

- янгынга каршы куркынычсызлыкны арттыру һәм кешеләр була торган урыннарда шартларны яхшырту буенча чаралар үткәрелә торган учреждениеләр өлешен 2029 елда 83 процентка кадәр арттыру;

- муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләренең гомуми санынннан энергияне сак тоту җайланмалары белән җиһазландырылган муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләре өлешен 2029 елда 82 процентка кадәр арттыру.

«Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре системасын үстерү» 4 нче ярдәмче программасына кушымта

**«Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре системасын үстерү» 4 нче ярдәмче программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 4 нче ярдәмче программа чараларын финанслау**

| Төп чаралар атамасы | Башкару-чылар | Төп чаралар-ны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләр-не бәяләү индикатор-лары, үлчәү берәмлек-ләре | Индикаторлар күрсәткечләре | | | | | | Финанслау чыганагы күрсәтелгән финанслау, мең сумнарда | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | База 2024 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 |
| **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **6** | **7** | **8** | **9** | **10** | **11** | **12** | **13** | **14** | **15** |
| Максат: сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре системасын саклау, ныгыту һәм үстерү | | | | | | | | | | | | | | |
| Бурыч: балалар сәнгать мәктәпләрендә белем бирү буенча сыйфатлы хезмәтләр күрсәтү өчен шартлар булдыруны тәэмин итү, талантлы яшьләрне ачыклау һәм аларга ярдәм итү, үсеп килүче буынга уңышлы социальләшү һәм иҗади яктан нәтиҗәле үсеш өчен мөмкинлекләр тудыру | | | | | | | | | | | | | | |
| Төп чара: өстәмә белем бирүне оештыру | | | | | | | | | | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Балалар-ның фестиваль-конкурс хәрәкәт-ләрендә һәм чараларда катнашуы | Мәдәният идарәсе, балалар музыка мәктәбе, балалар рәсем сәнгате мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе | 2025-2029 | Чараларга йөрүләр саны, мең кеше | 50,0 | 56,0 | 62,0 | 68,0 | 74,0 | 80,0 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар |
| | Мәдәният идарәсе, балалар музыка мәктәбе, балалар рәсем сәнгате мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе | 2025-2029 | Бюджет нигезендә белем алучылар-ның гомуми саныннан барлык дәрәҗәдәге фестиваль-конкурслар хәрәкәтенә җәлеп ителгән балалар өлеше, % | 74 | 75 | 75,5 | 76 | 76,5 | 77 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар |
| Белем бирү өлкәсен-дәге иҗади проект- | Мәдәният идарәсе, балалар сәнгать мәктәбе | 2025-2029 | Белем бирү өлкәсендә ярдәм күрсәтелгән иҗади инициатива- | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара- | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара- | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара- | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара- | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ларны үстерү | | | лар һәм проектлар саны | | | | | | | лар | лар | лар | лар | лар |
| Балалар сәнгать мәктәбенә бюджет урыннар-ына кабул итү өчен кандидат-ларны сыйфатлы сайлап алуны оештыру | Мәдәният идарәсе, балалар музыка мәктәбе, балалар рәсем сәнгате мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе | 2025-2029 | Балалар сәнгать мәктәбендә белем алуга бер бюджет урынына кандидатлар (кабул ителүчеләр һәм кабул ителгәннәр нисбәте) саны, кеше | 2,7 | 2,7 | 2,7 | 2,7 | 2,7 | 2,7 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар |
| Балалар сәнгать мәктә-бендә өлкән сыйныф укучы-ларына һөнәри юнәлештә белем бирү эшен гамәлгә ашыру | Мәдәният идарәсе, балалар музыка мәктәбе, балалар рәсем сәнгате мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе | 2025-2029 | Балалар сәнгать мәктәпләрен тәмамлап, мәдәният һәм сәнгать буенча урта һәм югары уку йортларында профильле белем алуны дәвам иткән балалар өлеше, % | 13 | 13 | 13 | 13 | 13 | 13 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар |
| Белем бирү | Мәдәният идарәсе, | 2025-2029 | Бюджет нигезендә | 77,0 | 78,0 | 78,0 | 79,0 | 79,0 | 80,0 | Бюд-жет, | Бюд-жет, | Бюд-жет, | Бюд-жет, | Бюд-жет, |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| оешма-сында сәнгать өлкәсен-дәге өстәмә башлан-гыч һөнәри програм-маларны бюджет нигезендә гамәлгә ашыру | балалар музыка мәктәбе, балалар рәсем сәнгате мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе | | белем алучылар-ның гомуми санынннан белем бирү оешмасында сәнгать өлкәсендәге өстәмә башлангыч һөнәри программа-ларны бюджет нигезендә үзләштерүче балалар өлеше, % | | | | | | | бюд-жеттан тыш чара-лар | бюд-жеттан тыш чара-лар | бюд-жеттан тыш чара-лар | бюд-жеттан тыш чара-лар | бюд-жеттан тыш чара-лар |
| | | | Бюджет нигезендә белем алучылар-ның гомуми санынннан белем бирү оешмасында өстәмә гомуми белем, гомуми үсеш программа-ларын | 23,0 | 22,0 | 22,0 | 21,0 | 21,0 | 20,0 | Бюд-жет | Бюд-жет | Бюд-жет | Бюд-жет | Бюд-жет |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | үзләштерүче балалар, шул исәптән сәламәтлеге ягыннан мөмкинлек-ләре чикле балалар өлеше, % | | | | | | | | | | | |
| Белем бирү буенча түләүле хезмәтләр күрсәтү | Мәдәният идарәсе, балалар музыка мәктәбе, балалар рәсем сәнгате мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе | 2025-2029 | 18 яшькә кадәр белем алучылар (түләүле нигездә) саны, кеше | 4000 | 4002 | 4004 | 4006 | 4008 | 4010 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар |
| | | | 18 яшьтән белем алучылар (түләүле нигездә) саны, кеше | 310 | 310 | 310 | 310 | 310 | 310 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар |
| Төп чара: балалар җыелма иҗат коллективларын саклау һәм үстерү, аларга ярдәм итү | | | | | | | | | | | | | | |
| Балалар-ны мәдәни проект-ларны һәм гомум-шәһәр чаралар- | Мәдәният идарәсе, балалар музыка мәктәбе, балалар рәсем сәнгате мәктәбе, | 2025-2029 | Бюджет нигезендә белем алучылар-ның гомуми континген-тыннан җыелма массакүләм | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ын гамәлгә ашыруга җәлеп итү, шул исәптән масса-күләм башкару формасы аша | балалар сәнгать мәктәбе | | балалар коллектив-ларына җәлеп ителгән балалар өлеше, % | | | | | | | | | | | |
| | Мәдәният идарәсе, балалар музыка мәктәбе, балалар рәсем сәнгате мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе | 2025-2029 | Бюджет нигезендә белем алучылар-ның гомуми саныннан бөтенроссия һәм халыкара чараларда җиңгән һәм призлы урыннар яулаган балалар өлеше, % | 48,5 | 49 | 49,5 | 50 | 50 | 50,5 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар |
| Музыка һәм рәсем сәнгать өлкәсендә премия-ләр | Мәдәният идарәсе, балалар музыка мәктәбе, балалар | 2025-2029 | Укытучы-ларның гомуми саныннан һөнәри осталык | 400 | 402 | 404 | 406 | 408 | 410 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара- | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара- | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара- | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара- | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара- |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| бирүгә еллык конкурс-лар үткәрү, шулай ук педагог-ларның һөнәри осталык һәм төрле дәрәҗә-дәге грантлар бирү буенча конкурс-ларда катнашу-ын тәэмин итү | рәсем сәнгате мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе | | конкурслар-ында җиңгән һәм призлы урыннар яулаган, шулай ук төрле премияләргә лаек булган һәм грантлар откан педагоглар саны, кеше | | | | | | | лар | лар | лар | лар | лар |
| Төп чара: матди-техник базаны үстерү һәм ныгыту | | | | | | | | | | | | | | |
| Муници-паль бюджет өстәмә белем бирү учрежде-ниеләре-нең | Мәдәният идарәсе, муници-паль мәдәният учрежде-ниесе | 2025-2029 | Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учрежде-ниеләрендә хезмәт күрсәтүнең сыйфатын | 45 | 45 | 45 | 45 | 46 | 46 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| матди-техник базасын ныгыту | | | күтәрү (сатып алынган җиһазлар-ның, мебельнең булганнары-на карата, шулай ук ремонтлан-ган биналарның булганнары-на карата нисбәте), % | | | | | | | | | | | |
| Төп чара: сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләрендә җәмәгать куркынычсызлыгын һәм аларның террорчылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | |
| Муници-паль бюджет өстәмә белем бирү учрежде-ниеләре эшчәнле-генең янгынга каршы курky-нычсыз-лыгын тәэмин | Мәдәният идарәсе, муници-паль бюджет өстәмә белем бирү учрежде-ниесе | 2025-2029 | Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учрежде-ниеләренең гомуми саныннан янгынга каршы куркыныч-сызлыкны арттыру һәм кешеләр була торган урыннарда | 80 | 81 | 81 | 82 | 82 | 83 | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар | Бюд-жет, бюд-жеттан тыш чара-лар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| итү | | | шартларны яхшырту буенча чаралар үткәрелә торган учреждениеләр өлеше, % | | | | | | | | | | | |
| Кешеләр күпләп җыела торган урыннарның (муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләреннән) терроччылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү | Мәдәният идарәсе, муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе | 2025-2029 | Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләренең гомуми санынан кешеләр күпләп җыела торган урыннарның терроччылыкка каршы сакланганлык дәрәҗәсен арттыру буенча чаралар үткәрелә торган | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләре өлеше, % | | | | | | | | | | | |
| Төп чара: сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре тарафыннан энергияне сак тотуны һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруны тәэмин итү | | | | | | | | | | | | | | |
| Энергияне сак тоту технологияләрен кулланып, энергия ресурсларын сак тоту буенча чаралар үткәрү | Мәдәният идарәсе, муниципаль мәдәният учреждениесе | 2025-2029 | Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләренең электр энергиясен куллануын 2024 елга карата киметү, % | - | 3,7 | 3,8 | 3,8 | 3,9 | 3,9 | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар |
| | | | Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләренең гомуми саныннан энергияне сак тоту җайланмалары белән | 80 | 80 | 81 | 81 | 82 | 82 | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар | Бюджет, бюджеттан тыш чаралар |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | җиһазлан-дырылган муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учрежде-ниеләре өлеше, % | | | | | | | | | | | |
| 4 нче ярдәмче программа буенча барлыгы, шул исәптән | | | | | | | | | | 730 173,8 | 733 392,9 | 733 392,9 | 733 392,9 | 733 392,9 |
| Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары хисабына | | | | | | | | | | 692 923,8 | 696 142,9 | 696 142,9 | 696 142,9 | 696 142,9 |
| Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләренең агымдагы эшчәнлеген муниципаль йөкләмә кысаларында тәэмин итү | | | | | | | | | | 676 481,3 | 679 700,4 | 679 700,4 | 679 700,4 | 679 700,4 |
| Балаларның җыелма иҗат коллективлары эшчәнлеген тәэмин итү | | | | | | | | | | 2000,0 | 2000,0 | 2000,0 | 2000,0 | 2000,0 |
| Максатчан субсидия кысаларында муниципаль милекне тиешле хәлдә карап тотуны тәэмин итү, авария очракларын бетерү һәм күзәтчелек органнары күрсәтмәләрен үтәү буенча эшләр башкару | | | | | | | | | | 1896,5 | 1896,5 | 1896,5 | 1896,5 | 1896,5 |
| Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләренең террорчылыкка каршы сакланган булуларын тәэмин итү буенча эшләрне оештыру һәм үткәрү | | | | | | | | | | 12 522,5 | 12 522, 5 | 12 522, 5 | 12 522, 5 | 12 522, 5 |
| Сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган өстәмә белем бирү учреждениеләре объектлары тарафыннан энергияне сак тотуга һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру | | | | | | | | | | 23,5 | 23,5 | 23,5 | 23,5 | 23,5 |
| бюджеттан тыш чаралар хисабына | | | | | | | | | | 37 250,0 | 37 250,0 | 37 250,0 | 37 250,0 | 37 250,0 |
| Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауда катнашу | | | | | | | | | | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 | 0,0 |

Файдаланылган кыскартулар исемлеге:
бюджет – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты;
Мәдәният идарәсе – Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе.

«2025-2029 елларга
Казан шәһәрендә мәдәниятне
үстерү» муниципаль программасына
7 номерлы кушымта

**«Мәдәният өлкәсендә башка мәсьәләләр»**
**5 нче ярдәмче программасы**

## I. 5 нче ярдәмче программа паспорты

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программаның атамасы | «Мәдәният өлкәсендә башка мәсьәләләр» (алга таба – 5 нче ярдәмче программа) |
| Муниципаль заказчы | «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Мәдәният идарәсе) |
| 5 нче ярдәмче программаны төп эшләүче | Мәдәният идарәсе |
| 5 нче ярдәмче программаны башкаручылар | Мәдәният идарәсе, Казан шәһәренең Мәдәният идарәсе карамагындагы бюджет һәм автоном учреждениеләре, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе, «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе |
| 5 нче ярдәмче программаның максаты | Мәдәният тармагы инфраструктурасын үстерү һәм билгеләнгән функцияләрне һәм вәкаләтләрне башкару кысаларында финанс ресурслары белән нәтиҗәле идарә итү өчен шартлар булдыру |
| 5 нче ярдәмче программаның бурычлары | 1. Мәдәният өлкәсендә муниципаль бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыру, актуаль иҗади һәм белем бирү инициативаларына адреслы-максатчан ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашыру.<br>2. Балалар сәнгать мәктәпләрендә проектлар белән идарә итүне үстерү. |

<table>
<tr><td></td><td>3. Муниципаль мәдәният учреждениеләрендә проектлар белән идарә итүне үстерү.<br>4. Әһәмиятле гомумшәһәр массакүләм мәдәни чараларны озак вакытка планлаштыруны тәэмин итү.<br>5. Казан шәһәренең мәдәният учреждениеләрен аларның эш нәтиҗәлелеген, шулай ук алар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең төрлелеген һәм сыйфатын арттыруны тәэмин итү максатыннан модернизацияләү</td></tr>
<tr><td>5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру вакыты</td><td>2025-2029 еллар</td></tr>
<tr><td>Елларга һәм чыганакларга бүлеп, 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме</td><td>5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 387 339,9 мең сумны тәшкил итә, шуларның 387 339,9 мең сумы – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары исәбеннән, 0,00 мең сумы – бюджеттан тыш чаралар исәбеннән, 0,00 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау.
<table>
<tr><th rowspan="4">Ел</th><th colspan="6">Акча күләме, мең сумнарда</th></tr>
<tr><th colspan="3">Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты</th><th rowspan="3">Бюджет-тан тыш чаралар</th><th colspan="2">Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауда катнашу</th></tr>
<tr><th rowspan="2">Барлы-гы</th><th colspan="2">шул исәптән Аппаратны карап тотуга чыгымнар</th><th rowspan="2">Барлы-гы</th><th rowspan="2">шул исәптән Аппа-ратны карап тотуга чы-гымнар</th></tr>
<tr><th>Барлыгы</th><th>Шул исәптән оешмалар милкенә салымны һәм җир салымын түләү</th></tr>
<tr><td>2025</td><td>77 097,1</td><td>12 015,2</td><td>664,7</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2026</td><td>77 560,7</td><td>12 412,3</td><td>664,7</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2027</td><td>77 560,7</td><td>12 412,3</td><td>664,7</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>2028</td><td>77 560,7</td><td>12 412,3</td><td>664,7</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
</table></td></tr>
</table>

<table>
<tr>
<td></td>
<td>
<table>
<tr><td>2029</td><td>77 560,7</td><td>12 412,3</td><td>664,7</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
<tr><td>БАР-ЛЫГЫ</td><td>387 339,9</td><td>61 664,4</td><td>3 323,5</td><td>0,0</td><td>0,0</td><td>0,0</td></tr>
</table>
Искәрмә: 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фаразлау характерында, аңа, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>5 нче ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган ахыргы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм 4 нче ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td>
<td>5 нче ярдәмче программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәге нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>
- кредиторлык бурычлары булган учреждениеләр саны һәм алар буенча түләү вакыты узган кредиторлык бурычлары суммасы – 0 берәмлек;<br>
- хезмәт хакын түләү вакыты буенча хокук бозу очраклары ачыкланган учреждениеләр саны – 0 берәмлек;<br>
- хезмәт өчен түләү фондын арттыру очраклары ачыкланган учреждениеләр саны һәм планлы хезмәт өчен түләү фондын арттыру күләме – 0 берәмлек;<br>
- хокук бозу очраклары ачыкланган учреждениеләр саны һәм аларда ачыкланган хокук бозулар саны – 0 берәмлек;<br>
- ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләрдән алынган керемнәр күләменең план күрсәткечләрен үтәү өлеше – 100 процент;<br>
- билгеләнгән контроль срокларда үтәлгән йөкләмәләр өлеше – 100 процент;<br>
- грантлар буенча билгеләнгән срокларда тапшырылган хисаплар өлеше – 100%;<br>
- муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләре тарафыннан конкурсларда (грантлы) катнашу өчен бирелгән гаризалар санын 2029 елда 19 га кадәр арттыру;<br>
- җиңүче дип танылган муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләре һәм муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан конкурсларда (грантлы) катнашу өчен бирелгән гаризалар санын 2029 елда 6 га кадәр арттыру;<br>
- муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан конкурсларда (грантлы) катнашу өчен бирелгән гаризалар санын 2029 елда 20 гә кадәр арттыру;<br>
- «Пушкин картасы» проектында катнашучы учреждениеләр санын саклап калу (муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениеләре);<br>
- «Пушкин картасы» проектында катнашучы учреждениеләр санын арттыру (муниципаль мәдәният учреждениеләре);</td>
</tr>
</table>

| | |
|---|---|
| | - «PRO.Культура.РФ» порталында ачылган сайтларның счетчиклары санын 2029 елда 25 кә кадәр арттыру (муниципаль мәдәният учреждениеләре өчен);<br>- «PRO.Культура.РФ» порталында оештырылган трансляцияләр санын 2029 елда 700 гә кадәр арттыру (муниципаль мәдәният учреждениеләре өчен);<br>- программалы массакүләм һәм массакүләм мәдәни чараларда катнашучылар санын 2029 елда 725000 кешегә кадәр арттыру;<br>- район чараларында катнашучылар санын 2029 елда 195000 кешегә кадәр арттыру;<br>- муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтүләрнең сыйфат дәрәҗәсен (сатып алынган җиһазларның, мебельнең булганнарына карата нисбәте) 41,8 процентка кадәр арттыру;<br>- муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан электр энергиясен куллануны 2024 елга карата 4,3 процентка кадәр киметү;<br>- муниципаль мәдәният учреждениеләренең гомуми санынннан энергияне сак тоту җайланмалары белән җиһазландырылган муниципаль мәдәният учреждениеләре өлешен 78,7 процентка кадәр арттыру;<br>- янгынга каршы куркынычсызлыкны арттыру һәм кешеләр була торган урыннарда шартларны яхшырту буенча чаралар үткәрелә торган муниципаль мәдәният учреждениеләре өлешен 83 процентка кадәр арттыру;<br>- кешеләр күпләп җыела торган урыннарның террорчылыкка каршы саклангanлык дәрәҗәсен арттыру буенча чаралар үткәрелә торган муниципаль мәдәният учреждениеләре, шулай ук шәһәр парклары һәм скверлары өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклап калу;<br>- «Россия – минем тарих» тарихи паркына килүчеләр санын 2029 елда 72000 кешегә кадәр арттыру;<br>- «Россия – минем тарих» тарихи паркында экскурсияләр санын 2029 елда 900 гә кадәр арттыру |

## II. 5 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру өлкәсенә характеристика, шул исәптән 5 нче ярдәмче программа хәл итәргә тиешле мәсьәләләр исемлеге

### Мәдәният өлкәсендә муниципаль идарә системасын үстерү

Мәдәният идарәсенең төп эшчәнлеге мәдәният белән бәйле җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру өлкәсендә идарә функцияләрен үтәү һәм муниципаль мәдәният учреждениеләре белән оештыру-методик яктан җитәкчелек итү, аларны матди-техник яктан тәэмин итүне оештыру, ягъни музей фондын саклау, өйрәнү һәм комплектлаштыру, халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне оештыру, милли традицияләрне саклау, шәһәр округында яшәүчеләрнең ялын оештыру һәм аларны мәдәният оешмалары тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру, сәнгать-эстетика юнәлешендә белем бирү учреждениеләре эшен тәэмин итү белән бәйле.

Мәдәният идарәсе милкен һәм акчаларын формалаштыру чыганагы – Мәдәният идарәсенең бюджет сметасы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчалары. Мәдәният идарәсенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге расланган бюджет сметасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Программа чараларын үтәүгә Казан шәһәре бюджетыннан бүлеп бирелгән акчаларның максатчан кулланылышы Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары нигезендә тикшерелә.

Казан шәһәре Думасының 2009 елның 29 апрелендәге 4-40 номерлы карары белән кабул ителгән «Казан мәдәнияте» концепциясе төп стратегик документ булып тора. Күрсәтелгән документ мәдәниятне кешеләрнең үз-үзләрен тоту нормаларын һәм эшчәнлек ысулларын билгели торган матди һәм рухи кыйммәтләр, традицияләр һәм ментальлек җыелмасы буларак карый. Шул рәвешле, шәһәрнең мәдәни сәясәте, мәдәният тармаклары кысаларыннан чыгып, шәһәрнең социаль һәм икътисади үсешендә мөһим факторга әверелә. Ул мөмкин кадәр күбрәк казанлыларны шәһәр тормышына җәлеп итүне, аларның мәдәни инициативаларына ярдәм күрсәтүне күздә тота.

2030 елга кадәр Казанның социаль-икътисади үсеш стратегиясен кабул иткәннән соң Казанда барган үзгәрешләр нигезендә мәдәниятне үстерү концепциясе һәм программалары да үзгәрергә тиешлеген исәпкә алып, шәһәрнең мәдәни сәясәтенә билгеле бер төзәтмәләр кертелде.

2030 елга кадәр Казанның социаль-икътисади үсеш стратегиясе максатларына ирешү өчен Татарстан башкаласына белемле, эшлекле, актив, талантлы, креатив халык кирәк. Мәдәният шәһәрнең кеше капиталын формалаштыра, шуңа күрә Мәдәният идарәсенең максаты – казанлыларның иҗади потенциалын үстерү. Әлеге максатка ирешү нәтиҗәсе исә креатив индустрияләрне үстерү булачак.

## Шәһәр парклары һәм скверлар

«Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе карамагында 2023 ел йомгаклары буенча 34 территория исәпләнә, аларның гомуми мәйданы 289,52 гектарны тәшкил итә.

2023 елда Казан шәһәренең яңартылган паркларында һәм скверларында «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан мәдәни, белем бирү һәм спорт юнәлешендә 1511 чара үткәрелде. Чараларга килүчеләрне генә исәпкә алсак та, аларда миллионнан артык кеше катнашты.

2022 ел Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елы дип игълан ителде. «Казан шәһәренең парклар һәм скверлар дирекциясе» муниципаль бюджет учреждениесе Мәдәният идарәсе белән берлектә урам артистларының шәһәр мәйданчыкларында чыгыш ясау тәртибен җайга сала торган «Art-проспект» онлайн-платформасын эшләтеп җибәрде. Платформа эшли башлаганнан бирле чыгыш ясауга 6803 гариза тапшырылган, уртача бер атна эчендә 430 га якын гариза кабул ителгән. Хәзерге вакытта урам артистлары 65 шәһәр мәйданчыгында чыгыш ясый ала, шуларның иң популяры – Бауман урамы. Онлайн-платформаны яхшырту өстендә эш дәвам итә, әмма бүген үк инде проект шәһәр белән иҗади кешеләр арасында диалог төзүдә мөһим адым булды дип әйтергә мөмкин.

## «Россия – минем тарих» тарихи паркы

«Россия – минем тарих» тарихи паркы – борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәр Россия тарихына багышланган бөтенроссия күргәзмә проекты. Анда 15 төбәк катнаша. Проектның бурычы – үткәндәге вакыйгаларга дөрес бәя бирү.

Мультимедиа чыганакларында тәкъдим ителә торган яңа форматтагы дүрт экспозиция («Рюриковичлар», «Романовлар», «Бөек тетрәнүләрдән Бөек Җиңүгә», «Россия – минем тарих») дәүләтнең формалашу этаплары турында сөйли. Парк экспозициясендә, Россия тарихы белән беррәттән, борынгы заманнардан алып безнең көннәргә кадәр Татарстан Республикасы тарихы, республика халыкларының тарихи-мәдәни мирасы да тәкъдим ителә.

Проектның уникальлеге шунда: бар мәгълүмат заманча мультимедиа җиһазлары – сенсорлы өстәлләр һәм экраннар, лайтбокслар һәм интерактив коллажлар ярдәмендә җиткерелә. Дүрт экспозициянең һәркайсында

видеоинфографика, анимация, өч үлчәмле модельләштерү һәм цифрлы реконструкцияләрнең төрле алымнары кулланыла.

Паркка килүчеләр – гади күзәтүчеләр генә түгел, ә Россия тарихында булып узган вакыйгаларның чын катнашучылары да: һәркем төп бәрелешләрнең шаһиты була, меңләгән мавыктыргыч фактларны белә, легендар «варяглардан грекларга» су юлы буйлап йөзә, Россия территориясенең ничек артуын бер минут эчендә күрә ала.

## Мәдәният тармагында проектлар белән идарә итүне үстерү

1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы «Мәдәният турында»гы Татарстан Республикасы законын гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләренең иҗат коллективлары проектларына ярдәм итү максатыннан, Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларына ел саен түбәндәге номинацияләр буенча конкурс үткәрә:

- «Тасвири сәнгать, дизайн һәм архитектура»;
- «Театр сәнгате»;
- «Музыка сәнгате»;
- «Хореография сәнгате, халык биюе»;
- «Цирк сәнгате»;
- «Сәнгать һөнәрләре һәм кәсепләре»;
- «Сәнгати-эстетик белем бирү»;
- «Культурология һәм сәнгать белеме өлкәсендә фәнни тикшеренүләр»;
- «Музей-күргәзмә эшчәнлеге»;
- «Китапханә эше»;
- «Әдәби эшчәнлек»;
- «Мәдәният һәм сәнгать белеме өлкәсендә журналистика»;
- «Халык иҗаты»;
- «Кинематография».

Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алучыларны билгеләү Советы ел саен әлеге максатларга бүлеп бирелә торган акчалар чикләрендә һәр номинация буенча грантлар алучыларны, грантларның күләмен һәм санын раслый. Казан шәһәре Башкарма комитеты белән грантларны финанслауда катнашу турында килешү имзалана, чөнки грантлар бүлеп бирү Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Татарстан Республикасының муниципаль

берәмлекләре бюджетларыннан тигез өлешле финанслауда катнашу шартларында гамәлгә ашырыла.

Казан шәһәренең муниципаль мәдәният учреждениеләре төрле дәрәҗәдәге грантлы конкурсларда актив катнашалар. Әйтик, 2023 елда муниципаль учреждениеләр түбәндәге конкурсларда җиңү яуладылар (отылган грантларның гомуми суммасы – 3 424 147 сум):

- Мәдәни инициативаларның Президент фонды (2 муниципаль учреждение, 434 758 сум);

- муниципаль мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре иҗат коллективларына ярдәм (4 учреждение, 1 500 000 сум);

- мәдәният учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм (9 кеше, 410 000 сум);

- иң яхшы мәдәният учреждениеләренә ярдәм (1 учреждение, 500 000 сум);

- СИБУРның «Яхшы эшләр формуласы» программасының грантлы конкурсы (1 учреждение, 458 562 сум);

- «Росмолодежь» яшьләр эшләре буенча федераль агентлык конкурсы (1 учреждение, 120 827 сум).

Грантларны бүлеп бирү Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетыннан тигез өлешле финанслауда катнашу шартларында гамәлгә ашырыла. Мәдәният-ял итү учреждениеләре конкрет номинация буенча грантлар алучылар булып торалар.

Грантлар алучылар хисап елыннан соң килә торган елның 1 июненә кадәр Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына грантлар түләүгә бүлеп бирелгән акчалардан максатчан файдалану һәм иҗади эшчәнлек нәтиҗәләре турында хисаплар тапшыралар.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2008 елның 22 декабрендәге 1015 номерлы әмерен үтәү йөзеннән мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең иң яхшы хезмәткәрләренә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын бирү буенча конкурс булдырылды. Әлеге конкурста Татарстан Республикасының мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләрендә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең мәдәният учреждениеләрендә эшләүче иң яхшы хезмәткәрләр катнаша. Ул югары һөнәри осталык һәм тармак үсешенә зур өлеш керткән өчен грант рәвешендә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру максатыннан дүрт номинация буенча үткәрелә:

- «Иң яхшы җитәкче» – мәдәният учреждениеләре җитәкчеләре арасында;

- «Профессионал» – мәдәният хезмәткәрләре арасында;

- «Таяныч һәм абруй» – мәдәният өлкәсендә кимендә 20 ел эшләгән мәдәният учреждениеләре ветераннары арасында;

- «Өметле киләчәк» – мәдәният өлкәсендә эшләүче, яше 30 дан артмаган, гомуми эш стажы 7 елдан ким булган хезмәткәрләр арасында.

Грантларның гомуми күләме елына 3 млн сумны тәшкил итә, шулардан:

- «Иң яхшы җитәкче» номинациясендә – һәркайсы 100 мең сумлык 7 грант;
- «Профессионал» номинациясендә – һәркайсы 70 мең сумлык 14 грант;
- «Таяныч һәм абруй» номинациясендә – һәркайсы 50 мең сумлык 18 грант;
- «Өметле киләчәк» номинациясендә – һәркайсы 30 мең сумлык 14 грант.

**Әһәмиятле гомумшәһәр массакүләм мәдәни чараларны озак вакытка планлаштыруны тәэмин итү**

Республикабыз башкаласын үстерүгә инновацион якын килү соңгы елларда Казан шәһәренең мәдәни сәясәтендә төп өстенлекле юнәлеш булды. Казан шәһәре мәдәнияте, шәһәрнең инвестицион һәм туристик җәлеп итүчәнлегенең мөһим ресурсы буларак, беренче чиратта түбәндәгеләргә юнәлтелгән:

- динамик үсештәге мегаполис буларак, Татарстан Республикасы башкаласының имиджын булдыру;
- шәһәрнең мәдәни мохитен модернизацияләү;
- туристлар килүне активлаштыру;
- шәһәр халкының ялын оештыру һәм аларны мәдәният учреждениеләре хезмәтләре белән тәэмин итү өчен тиешле шартлар тудыру.

Шәһәрнең мәдәни мохитен Россиядәге иң яхшы үрнәкләр һәм практикалар белән баетуга муниципаль мәдәният учреждениеләре зур өлеш кертә. Ел саен алар тарафыннан 7 меңнән артык чара үткәрелә. Алар арасында – 9 май, Россия көне, Сабан туе, Татарстан Республикасы көне һәм Казан шәһәре көне.

